ТЫРЫШЛЫК ӘҖЕРЕ
Нурлат районы фермеры урып-җыю эшләрен 5 көндә төгәлләгән

> 2

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК
Укучыларыбызның уй-фикерләре, истәлек-хатирәләре

> 3

ҮТКӘНГӘ СӘЯХӘТ
«ВТ» хәбәрчесе Әлки районының Сихтермә авылындагы ял комплексында булып кайтты

> 5



ӨМЕТЛЕ ТАСМА
Татарстанда тагын бер фильм прокатка чыга

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 109 (29076) | Сишәмбе | 1 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Фаҗига

КҮҢЕЛСЕЗ ЯЛ

Бер кара болыт 20 минутта дөньяның астын өскә китерде. Соңгы мәгълүматлар буенча, 29 июльдәге давыл аркасында, Идел буе федераль округында 10 кешенең гомере өзелде һәм 76 кеше зыян күрде. Һәлак булучыларның тугызы – Татарстаннан. Лаеш районында өстенә агач төшеп, 14 яшьлек кыз бала вафат булды. Мари Элда коточкыч фаҗига аркасында, Яльчик күле буенда ял иткәндә 8 якташыбыз һәлак булды.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының телеграм-каналы

«ВТ» журналисты үзе дә көчле җилнең агачларны сындырып атуының шаһиты булды. Бәхеткә, без йөргән районда давыл ныклап котырмады. Ә менә Казанның Яңа һәм Иске Салмачы, Залесный бистәләрендә, «Салават Күпере» торак комплексында яшәүчеләргә утсыз утырырга туры килде. Күп кенә йортларның түбәләрен җил кубарып атты. Яшен сугып, йортсыз калучылар, йортларына һәм машиналарына зыян килүчеләр дә бар. Казанда 23 кеше зыян күргән. 29 июльдә кич һәм 30 июль төнендә бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтенә гражданнардан 318 хәбәр килгән. Бу хакта «эшлекле дүшәмбе»дә Казан башкарма комитеты җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык һәм гражданнарны яклау мәсьәләләре буенча урынбасары Искәндәр Гыйниятуллин хәбәр итте.

Тынычланырга иртә!

Давыл алып килгән зыянны бетерү өчен, Казан мэриясе оператив штаб оештырды. Өзелгән электр чыбыкларын тоташтыру, ишегалдына ауган агачларны урнаштыру кебек эшләрне җаваплы оешмалар вакытында башкарды.

Татарстанда әле дә давыл кубарган түбәләрне ябалар, сынган агачларны барлыйлар. Үтеп китте, дияргә ярамый. Итәк-җиңнәр җыелган булырга тиеш! Татарстан Рәисе кушуы буенча, ял көнне Министрлар Кабинетында узган Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе утырышында табигать бәла-казалары китергән зыян һәм алга таба мондый күренешләргә ничек каршы тору хакында сөйләштеләр.

Татарстанның Премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин әйтүенчә, 14 торак пунктта, 4 районда 13 меңгә якын кеше утсыз калды. Ял көнне иртәнге сәгать 5тә чыбыкларны тоташтырып бетерделәр. Шулай ук 80 агач ауган, 17 автомобиль, 13 торак йортның түбәсе зыян күргән. Агачлар һәм тиешенчә ныгытылмаган конструкцияләр аву аркасында, 24 кеше, шул исәптән ике бала имгәнгән.

– Тынычланырга ярамый. Татарстанда җил дә, кызулар да булачак. Яшенле яңгыр, давыл, боз яварга да мөмкин, диләр. Һәр оешма алдан ук саклык чараларын күрсен, – диде ул.

Татарстан Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе җитәкчесе Сергей Захаров әйтүенчә, әле алдагы көннәрдә дә республикада шторм кисәтүе дәвам итәчәк.

– Давыл чыккан көнне безнең махсус станциядә җил тизлегенең 27 метр/секундка җитүе теркәлде. Көчле яшен техникаларыбызга зыян салды. Боз яуды, берничә минут эчендә 17 мм күләмендә явым-төшем теркәлде. Әле алга таба да һава торышының көйсезләнүе бар. Алдагы көннәрдә яшен булуы, боз явуы көтелә. Җил дә секундына 15–20 метр тизлектә булырга мөмкин, – диде Сергей Захаров.

> **Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Рәисе:**
> Үткән шимбә республикабызга зур кайгы китерде. Алдагы көнне кичен табигать казасы Татарстаннан 9 кешенең, шул исәптән 4 баланың гомерен өзгән. Күрше Мари Эл Республикасында Яльчик күле буенда кузгалган давыл агачларны палаткаларга аударган. Коткаручыларның бик тиз килеп җитүенә, ял итүчеләрнең үзләренең дә ярдәм кулы сузуына карамастан, 8 кеше һәлак булган. Фаҗигадә 3 баланың гомере өзелүе аеруча кызганыч, иң кечкенәсенә әле 1 яшь тә тулмаган. Һәлак булучылар – Казан, Биектау, Яшел Үзән һәм Питрәч районнарында яшәүчеләр.
> Шул ук вакытта Казанның ял базасында, агач авып, 14 яшьлек кыз һәлак булган. Коточкыч фаҗигадә үз якыннарын югалтучыларның барчасының авыр кайгысын уртаклашам. Хәзер Татарстаннан 11 кеше хастаханәләрдә дәвалана. Мин кирәкле медицина ярдәме күрсәтүне контрольдә тоту бурычы куйдым. Аларга тизрәк савыгуларын телим. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хәбәренә караганда, Татарстанда әле тагын давыл чыгарга мөмкин. Республикада яшәүчеләрнең һәркайсыннан игътибарлы булуларын, үзләрен һәм якыннарын саклауларын сорыйм!

Көчле җил чәршәмбе генә тыначак. Аннары инде тагын кызулар китә. Һава температурасы 28–31 градус булачак.

Давыл республикада 26 балалар лагерена зыян китергән. Татарстанның яшьләр эшләре буенча министры Ринат Садыйков әйтүенчә, бүген 111 лагерьда 18 мең бала ял итә. 15 палаткалы лагерь эшли. Яшел Үзәндә урнашкан «Пионер» лагере да – шундыйлардан. Палаткалар өстенә агачлар ауган. Әле ярый бу вакытта балаларны клубка керткәннәр. «Лагерьда эшләүчеләрнең вакытында сабыйларны җыеп алуы аркасында, бер кешегә дә зыян килмәгән, – диде министр. – Урманчылар барлык тирә-яктагы агачларны карап чыкса, тыныч булыр идек. Селкенеп кенә торучылары да бардыр».

Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров шунда ук җавап бирде. «Урманчылар эштә. Лаеш, Буа, Яшел Үзән, Питрәч, Биектау урманчылыкларына зыян килде. Агачлар күпләп аумаган. Без инде урыннарга чыктык. Куркыныч янаган агачларны барлыйбыз», – диде ул.

Ахыры 5 нче биттә >

Бетте

Татарстан Хөкүмәте COVID-19 пандемиясе чорында кертелгән чикләүләрне һәм ярдәм чараларын гамәлдән чыгарды. Бу хактагы карарны Премьер-министр Алексей Песошин имзалады. Документ Хокукый мәгълүматлар рәсми порталына урнаштырылган.

Шулай итеп, 88 боерык һәм карар үз көчен югалткан. Аерым алганда, табибларга кызыксындыру максатындагы түләүләр, коронавирус таралуны кисәтү чаралары, чир таралуга каршы көрәшү мәсьәләләре буенча проектлар, актлар әзерләү тәртибе турында төрле документлар. Шулай ук битлек режимы, QR-кодлар, үзизоляция турындагы документлар үз көчен югалткан.

Исегезгә төшерәбез: 13 июньдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, эпидемиологик вазгыятьнең тотрыклануы сәбәпле, республикада инфекциягә бәйле көчәйтелгән әзерлек режимын гамәлдән чыгарды.

Кәрзин кыйммәтләнгән

Татарстанда янә иң кирәкле азык-төлек җыелмасы кыйммәтләнгән. Июнь аенда ул 5283 сум тәшкил иткән. Май азагында исә 5068,37 сум булган. Шулай итеп, бер ай эчендә кәрзин бәясе 4,2 процентка үскән.

Шул ук вакытта июньдә республикада азык-төлек бәясе Идел буе федераль округының күпчелек төбәкләрендәгегә караганда арзанрак булган. Иң югары бәяләр Пермь краенда (5778 сум), Ульяновск өлкәсе (5635 сум) һәм Самара өлкәсендә (5600 сум) теркәлгән. Татарстанда бер кешегә туры килүче кәрзин бәясенең 23,3 проценты – икмәк, ярма, токмачка, 18,9 проценты – ит, 16,4 проценты – сөт ризыкларына, 21,6 проценты – яшелчә-җиләк-җимешкә, 5,1 проценты – балык, 5,3 проценты – май, 1,9 проценты – йомырка, 2,1 проценты – шикәр, 2,9 проценты башка ризыкларга туры килә.

Май азагында Идел буе федераль округында иң кирәкле азык-төлектән торучы кәрзин хакы 5217,86 сум тәшкил иткән. Бер ай эчендә ул 2,9 процентка кыйммәтләнгән.

Уңайлы юлны сайлаганнар

Дәүләт хезмәтләре порталындагы «Поступление в вуз онлайн» сервисы аша бюджет урыннарына кергән гаризалар саны буенча Татарстан лидерлыкка чыккан. Вице-премьер Дмитрий Чернышенко әйтүенчә, сервис аша барлыгы 550 меңнән артыграк абитуриент төрле юнәлеш буенча 2 миллионнан артык гариза тапшырган. Вузларга 930 мең чамасы кешедән җәмгысы 2,8 миллион гариза алынган.

Бюджет урыннарына кабул итү 25 июльдә төгәлләнгән. Түләүле урыннарга алу 20 августка кадәр дәвам итәчәк. Тапшырылган гаризалар саны ягыннан, Татарстаннан тыш, Мәскәү һәм Санкт-Петербург беренчелеккә чыккан.

Сатучыга – дәресләр

Татарстанда маркетплейсларда сатучыларга бушлай дәресләр – форум-марафоннар үткәрелә башлый. Шулай итеп, теләгәннәр барчасы интернет аша товар карточкасын дөрес тутырырга, көндәшләренекенә анализ ясап, үз товарына реклама ясарга өйрәнәчәк. Биремнәрне уңышлы үтәүчеләргә электрон сертификатлар тапшырылачак.

Татарстан Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Габделганиев әйтүенчә, 2021 елда Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча кабул ителгән электрон сәүдәне үстерү программасы нигезендә, соңгы ике ел эчендә республикадан маркетплейсларда сатучылар саны 14 тапкыр арткан. Электрон сәүдә сатучыларның 33 проценты чамасы өчен төп яки бердәнбер керем чыганагы булып тора.

Барлыгы 4 форум-марафон үткәрелә. 14–28 августта – «PRO_Wildberries», «18 сентябрь – 2 октябрьдә – «PRO_Ozon», 16–30 октябрьдә – «PRO_Яндекс Маркет», 13–7 ноябрьдә – «PRO_KazanExpress» бушлай дәресләр уздырачак.

Моның өчен МСП.рф порталында теркәлергә мөмкин.

Яңалык

Август ае үзгәрешләре

Илдар Мөхәммәтҗанов

Эшләүчеләрнең пенсиясе артачак, ә ришвәтчеләрдән тартып алынган мөлкәт аукционнарда сатыла башлаячак.

✓1 августтан Россиядә өченче валюта – цифрлы сумнар пәйда булачак. Яңа акчадан теләсә нинди алыш-бирештә, шулай ук мөлкәтне бүлгәндә файдаланып булачак. Аны мираска калдырырга да мөмкин. Электрон акча бу. Ул интернет-платформаларда цифрлы акча янчыкларында сакланачак. Барысы да Үзәк банк карамагында булачак. Мондый платформаларга теләсә кайсы банкның кушымтасы аша кереп булачак. Цифрлы сумның бәясе гадәттәге акчаныкына тигез.

✓Эшләүчеләрнең, шулай ук очучы һәм шахтерларның пенсиясе артачак. Өстәмәне, узган елда эшләп, эш бирүчеләре пенсия системасына иминият кертемнәре түләгән пенсионерлар алачак. Пенсия автомат рәвештә, пенсия системасына кергән акчадан чыгып артачак. Өстәлгән акчаның күләме кешенең узган елда күпме эшләвенә һәм кертем күләменә бәйле булачак.

Гамәлдәге закон нигезендә, пенсия күләме елына 4 тапкыр: 1 февральдән, 1 май, 1 август һәм 1 ноябрьдән арта.

✓Мобилизация турында повесткалар үзгәрә. Чакыру кәгазьләре «срочник»ларныкына охшап калачак. Документның өске өлеше генә аерылып торачак: анда хәрби комиссариатка барырга тиешле көн һәм вакыт, шулай ук мобилизация үткәрү турында Президент указы номеры күрсәтеләчәк. Повестка Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинет аша электрон рәвештә кабат җибәреләчәк.

Повестка алып та, военкоматка барып күренмәүчеләрне чикләүләр көтә. Алар машина йөртү хокукыннан, кредит алудан, күчемсез милек белән алыш-бирешне теркәүдән вакытлыча мәхрүм ителәчәк.

✓Ришвәтчеләрдән тартып алынган мөлкәт аукционнарда сатыла башлаячак. Кыйммәтле торак базар бәясеннән ике тапкыр һәм аннан артыграк бәядән сатылачак. Мөлкәт өч ай эчендә сатылмаган очракта, биш процентка кимрәк бәядән янә аукционга чыгарыла. Икенче тапкыр да яңа хуҗасы табылмаса – алты айдан соң өченче аукцион үткәреләчәк. Хәзерге вакытта дәүләт фондында 140ка якын конфискацияләнгән торак объекты бар. Ләкин моңа кадәр закон аны сату мөмкинлеге бирмәгән.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Анна КУЗНЕЦОВА, Россия Дәүләт Думасы вице-спикеры:

Хәзерге вакытта махсус хәрби операция зонасында булган, әмма хәрби госпитальдә эшләмәүче табибларга да өстәмә социаль түләүләр билгеләргә кирәк. Юкса шулкадәр кирәк булган табиблар саны кимүгә таба китәргә мөмкин. Шуңа күрә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгына, үз гомерләрен аямаган барлык табибларга да ярдәм күрсәтүләрен сорап, мөрәҗәгать юлладык.

(«Парламентская газета» басмасына биргән әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – КРЕДИТ

«Скоринг бюро» мәгълүматларына караганда, банклар бу елның 6 аенда 18 млн куллану кредиты биргән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, үсеш 112,5 процентны тәшкил итә.



Кредитның уртача суммасы............**196,6 мең сум (+2,8%)**

Кредит вакыты ....**27,5 ай (–9,6%)**

Автокредитлар.................................**383,85 мең (+65,2%)**

Кредитларның гомуми суммасы....**493,92 млрд сум (+69%)**

Юкка чыгарылды

Узган айда Россия гаскәрләре Украина коралллы көчләренең 20824 хәрби хезмәткәрен юкка чыгарган. Россия оборона министры, армия генералы Сергей Шойгу әйтүенчә, каршы якның 2227 берәмлек коралы, шул исәптән 10 «Leopard» танкы, Америкадан китерелгән 11 «Bradley» пехота хәрби машинасы һәм 40 M777 артиллерия системасы, Бөекбритания, АКШ, Германия, Франция һәм Польша биргән 50 үзйөрешле артиллерия җайланмасы юк ителгән.

Узган атна ахырында – 26 һәм 27 июльдә Работино авылы тирәсендә 400гә якын Украина хәрбие һәм барлыгы 63 берәмлек бронетехника юкка чыгарылган.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

НИГЕР: ЧИРАТТАГЫ ТҮНТӘРЕЛЕШ

Россия – Африка саммиты башланыр алдыннан Үзәк Африкадагы фәкыйрь дәүләтләрнең берсе Нигерда дәүләт түнтәрелеше булды. 27 июль иртәсендә Президент гвардиясе башлыгы генерал Гомәр Тчиани җитәкчелегендәге фетнәчеләр ил лидеры Мөхәммәд Базумны хакимлектән читләштерүләрен игълан итте.

Элекке француз колониясе булган бу дәүләт әле дә Париж йогынтысында. Анда французларның һәм Американың хәрби базасы бар. Соңгы вакытларда Парижны Үзәк Африкадан кызу темплар белән куалар. Нигерның күршесе Мали һәм тагын берничә дәүләт, француз гаскәрләрен куып, ярдәмгә Пригожинның «Вагнер» хосусый хәрби компаниясен чакырды. Нигер «Вагнер» белән хезмәттәшлектән баш тарткан иде. Менә шул дәүләттә вакыйгалар кискен куерды. Фетнә башта Президент сакчыларының гвардия башлыгы Тчианиның эштән алынуына ризасызлык рәвешендә кузгалды. Армия үзенең Президентны яклавын белдерде, хәтта илнең кораллы көчләре Президент сараен штурмлар дип тә көтелде. Әмма берникадәр вакыт үтүгә, армиянең дә путч тарафдарлары ягына чыгуы мәгълүм булды.

Нигерда (һәм гомумән Африкада) фетнәләр бик еш оештырыла.

Бу фәкыйрь ил уран экспорты белән танылган. Дөньяда җитештерелгән уранның 5 проценты – шул илнеке. Төп сатып алучы – Франция. Парижның фетнәгә кискен каршы чыгуы аңлашыла. Җитмәсә, гыйсъянчылар ил башкаласындагы француз илчелеген яулап алдылар диярлек, аның янында, французларның илдән китүен таләп итеп, зур акция уздырдылар, Россия флагларын болгадылар. Макрон бу уңайдан «Франциягә һәм аның мәнфәгатьләренә бернинди һөҗүмгә дә түзеп тормаячагын» игълан итте. Көнбатыш Африка илләрен берләштергән ЭКОВАС оешмасы хунтадан «барысын да кире кайтару»ны таләп итте. Нигерның ЭКОВАС банкларындагы активлары туңдырылды, оешма масштаблы санкцияләр әзерләвен хәбәр итте. Хәрби тыкшыну ихтималы да бар, ләкин зур түгел. Базум хакимлеген корал көче белән торгызу турында янау бар үзе. АКШның дәүләт секретаре Блинкен да ЭКОВАС карарын хуплавын әйтте.

Нигердагы фетнә дөнья базарлары өчен көрәшнең кискенләшүен күрсәтә. Уран ягулыгының өчтән бер өлешен шул Үзәк Африка иленнән алган французлар вазгыятьнең үзләренә каршы булуына түзеп тормас, мөгаен. Болай да алар Африкадан байтак чигенделәр. Көнбатыш Россиянең Африкадагы йогынтысы көчәюне Кытай мәнфәгатьләренә хезмәт итә дип саный. Кара континентта вазгыять тиз үзгәрүчән. Кайчак киеменнең уңын сулга алыштырып кияргә дә өлгермисең, хакимият алмашына. Көнбатыш әлегә гыйсъянчыларга финанс басымы ясый. Нигерның яңа хакимияте финанс министрыннан акчаның кая югалуын ике көн эчендә аңлатырга куша. Канәгатьләнерлек җавап булмаса, атарга вәгъдә итәләр.

Россиядә

РОССИЯ – АФРИКА: ДУСЛЫК НЫГЫЙМЫ?

Кара континент вәкилләренең Санкт-Петербургка күмәк визиты үткән атнадагы Россия сәяси тормышында үзәк вакыйгага әверелде. Саммит Россиягә үзенең изоляциядә түгеллеген дәлилләү өчен дә кирәк иде. Базарлар өчен барган көрәштә яңа мәйданнар яулап алу максаты да мөһим.

Африка илләре Россия кулыннан шактый ук мул бүләк алдылар: 23 миллиард доллар бурыч гамәлдән чыгарылды, 300 мең тоннага якын ашлык бушка вәгъдә ителде. Бурычларны кичерү традициясе совет вакытыннан ук килә. Үсеп килүче илләргә әҗәткә бирелгән акча гадәттә кире кайтарып алынмый. Африка лидерлары белән саммитның алдагысы 2019 елда булган һәм ул чакта да Путин кара континентка 20 миллиард доллар бурычны кичерүне игълан иткән. Бу юмартлыкны африкалылар ни дәрәҗәдә бәялиләр?

Дүрт ел элек Сочида үткәрелгән саммитка 54 ил вәкиле килгән, шуларның 45е иң югары җитәкчеләрне юллаган. Петербург саммиты исә 49 ил вәкилен генә җыйган. Шуларның бары тик 17се генә лидерларын җибәргән, 5 ил вице-президент вазыйфасындагы шәхесләр озаткан, 4 хөкүмәт җитәкчесе килгән. Калган илләр министр дәрәҗәсендәге вәкилләрне генә озаткан. Кремльнең рәсми вәкиле Дмитрий Песков бу хакта: «...Но это и неприкрытое наглое вмешательство США, Франции и других государств. Через их дипредставительства были попытки оказать давление на руководство этих стран с тем, чтобы воспрепятствовать их участию в форуме. Это действительно факт. Он совершенно возмутительный», – диде.

Әмма Кремльдә күңел төшермәделәр. Владимир Путин авызыннан бик еш Мәскәү белән Африка башкалаларының дөньядагы хәлләргә карашлары туры килүе турында сүзләр яңгырады. Африка белән дуслык икътисадый дивидендлар да бирә. Путин үткән ел сәүдә әйләнешенең 18 миллиард долларга җитүен билгеләп үтте. Дөрес, бу сан Евросоюз белән Африка арасында 412,2 миллиард долларлык, Кытай белән 212,8 миллиард долларлык сәүдә әйләнеше янында бик кечкенә. АКШ та африкалылар белән үткән ел 68,2 миллиард долларга сәүдә иткән. Хәтта Төркия дә 2020 елдагы 23,4 миллиард долларлык сәүдә әйләнешен 2022 елда 32,8 миллиардка җиткергән. Эш монда дуслык белән генә хәл ителми. Африка илләре тышкы базарлардан технологик товарлар сатып ала. Россия исә күбрәк чимал сату белән мәшгуль, технологик товарларны безнең үзебезгә дә тышкы базарлар бирә. Африка чималыннан товар җитештерә торган мәйданнар исә бездә юк диярлек. Шуңа карамастан, быелгы сәүдә әйләнеше 35 процентка артуда икән.

Көньяк Африка Республикасы Президенты Сирил Рамафоса Кремль күрсәткән игелекне тулысынча ук бәяләп бетермәде. Ул Мәскәүгә хәер сорап килмәүләрен әйтеп, «ашлык килешүе»н дәвам итүне сорады. Саммит кысасында Путин күп проблемаларга тукталды, Әрдоган белән чәршәмбе көнне телефоннан сөйләшәчәген әйтте. Бәлки, «ашлык килешүе» шул сөйләшүдән соң тормышка ашырыла да башлар.

БЕР ГАСЫРДАН АРТЫК

Спорт кына түгел бу

Узган атнада Россия волейболының 100 еллыгын билгеләп үттеләр. Беренче очрашу 1923 елның 28 июлендә Мәскәүдә узган. Шул уңайдан оештырылган «Калининградтан Камчаткага кадәр» фестиваленә Татарстан да кушылды. Казанда Мәктәп волейбол лигасының Җәйге Кубогы узды.

tatarstan.ru

Волейболны һәр кеше уйный ала. Артык чыгымы да юк, махсус әзерлек тә таләп ителми. Әле берләштерә торган ягы да бар. Казанда узган пляж волейболы ярышы моны янә раслады. Әйтик, дөньякүләм танылган футболчыларның авыл малайлары белән бергә туп типкәнен күз алдына китерү кыенрак. Ә менә волейболда мөмкин хәл бу. Шимбә көнне «Зенит-Казан» һәм «Динамо Ак барс» уенчылары мәктәп укучылары белән туп сукты. Күз алдына гына китерегез: Олимпия чемпионы, 5 тапкыр Чемпионнар Лигасын, ә 8 мәртәбә Россия чемпионатын откан, күп тапкыр иң яхшы уенчы булып танылган Максим Михайлов 35 градус эсседә сабыр гына 14–15 яшьлек малайларның комга чыкканын көтеп тора. Көтә, чөнки алар бер командада. Бергә булмасаң, җиңү мөмкин түгел.

Мәктәп волейбол лигасы Татарстанда 2018 елда оештырылды. Бу эшкә барлык шәһәр һәм районнар кушылды. Бездән күреп, әлеге проект башка төбәкләрдә дә барлыкка килде. Хәзер мондый ярыш ил күләмендә дә оештырыла. Ә Җәйге Кубок өчен көрәшергә район һәм шәһәрләрдән 60 команда җыелды. Танылган спортчылар белән бергә уйнау аларның осталыгын да арттыра, күңелен дә күтәрә. Монысы, ниһаять, үзебездә профессиональ клубларда, җыелма командаларда чыгыш ясый алырлык уенчылар тәрбияләү өчен дә кирәк. «Бу мәсьәләгә без дә игътибар бирәбез. Эшебезне дәвам иттерсәк, үзебезнең егетләр һәм кызлар үсеп җитәр һәм алар республика өчен җанын-тәнен биреп уйнарлар дип өметләнәбез», – диде Дәүләт Советы Рәисе, Татарстанның Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин Казансу буенда узган турнирның ачылу тантанасыннан соң.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, республикада һәр шәһәрдә, авылда, уку йортында волейбол уйнар өчен мөмкинлекләр бар. Бу спорт төре белән Татарстанда 42 меңнән артык кеше шөгыльләнә. Моның өчен 286 спорт комплексы, 142 ачык мәйданчык эшли, 57 урында пляж волейболы уйнарга мөмкин, 34 спорт мәктәбе һәм аларның бүлекләре бар. Ел саен 120 турнир оештырыла. «Волейболны алга таба да үстерәчәкбез. Бу спорт төренең тәрбия ягыннан да файдасы бар, ул команда рухын һәм ватанпәрвәрлек хисен ныгыта», – диде парламент башлыгы.

Август ае үзгәрешләре

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

✓ Кайбер дәүләт хезмәткәрләренә вазыйфада эшләүнең чик яшен 5 елга арттырачаклар. Биредә сүз төбәкнең законнар чыгару аппаратындагы җитәкче вазыйфаларын биләүчеләр турында бара. Моңа кадәр төбәкләрдә мондый вазыйфада 65 яшькә кадәр генә эшләргә мөмкин иде. Хәзер – 70 яшькә кадәр.

✓ Чит ил агентларына законсыз эшчәнлек алып барырга ярдәм иткән кешеләр һәм оешмаларны штрафка тарта башлаячаклар. Башта алар Юстиция министрлыгыннан күрсәтмә алачак. Ә күрсәтмәне вакытында үтәмәгән очракта, 30 меңнән 50 мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга 70 меңнән 100 мең сумга кадәр штраф салыначак.

✓ Төзелеп бетмәгән йортка хокукны теркәү гадиләштерелә. Аерым алганда, моның өчен техник план таләп ителмәячәк.

✓ Югары уку йортларында «Алдынгылар хәрәкәте» бүлекләре ачылачак. Россия Президенты Владимир Путин быелдан башлап һәр ел саен балалар һәм яшьләр хәрәкәтенә 21,35 миллиард сумнан артыграк күләмдә акча күчерү бурычы куйган. 4 августтан оешма әлеге акчадан файдалану хокукы ала. Ул шулай ук университетларда башлангыч бүлекләрен булдыру мөмкинлегенә ия булачак. Шулай итеп, 18 яшькә җитмәгән абитуриентлар – хәрәкәт эшендә катнаша, ә студентлар остазларга әйләнә алачак. Мондый бүлекләрнең эшен Мәгариф һәм фән министрлыгы җайга сала.

✓ Иң кирәкле дарулар исемлеге киңәйтеләчәк. Хөкүмәтнең бу җәһәттән боерыгы 13 августтан үз көченә керә. Исемлеккә, шул исәптән, балаларны каты һәм хроник чирләрдән дәвалау өчен кирәкле яңа дарулар кертелгән. Мондый даруларның бәясен дәүләт контрольдә тота. Бу исемлеккә 800дән артыграк дару кертелгән.

✓ Хөкем ителгәннәр таксида эшли алмаячак. Таксистлар 31 августка кадәр эш бирүчеләренә хөкем ителү очракларына дучар булмаулары турында белешмә тапшырырга тиеш. Юкса алар эштән җибәреләчәк.

✓ Медицина кирәк-яраклары һәм сокларга мәҗбүри маркировка кертелә. Медицина әйберләрен, балалар өчен су, хәмерсез эчемлекләр һәм соклар, кәнәфи-коляска, БАД һәм антисептикларны маркировкалау буенча эксперимент 31 августта тәгәлләнә. Шуннан соң бу эш мәҗбүригә әйләнә.

БУРЫЧ АРТКА СӨЙРИ

Яшәеш

10 миллиард сум. Татарстанда яшәүчеләрнең коммуналь хезмәтләр өчен әнә шулкадәр бурычы җыелган. Ил буенча әҗәт күләме исә гомумән куркыныч санга – 900 миллиард сумга җиткән. Халыкның идарәче оешмаларга бурычы елдан-ел арта, ди белгечләр. Ут һәм су өчен түләргә теләмиләрме, әллә бәяләр үскән саен, кесә такыраямы? Белгечләрдән әнә шул хакта сорадык.

Казанда яшәүче берәү әле шушы арада гына идарәче оешмага коммуналь хезмәтләр өчен 200 мең сум бурычын каплаган. Эш шунда ки, әҗәтлене судка биргәннәр. Тикшерү барышында бу кешенең автомобиле, анысы да килде-китте генә түгел, ә кыйммәтле чит ил машинасы булуы ачыкланган. Суд приставлары әнә шул милеккә арест салган. «Тимер ат»сыз калгач, бурычны түләргә дә акча табылган. Коммуналь хезмәтләр өчен әҗәтлеләр арасында төрлесе бар, билгеле. Авылларда ут һәм су өчен вакытында түли алмаган аз керемле гаиләләргә мәчеттә сәдакага дип җыелган акчадан ярдәм итү очраклары да бар.

Бу елның беренче яртысына караган мәгълүматлар буенча, республикада яшәүчеләрнең коммуналь хезмәтләр өчен 9,4 миллиард сум бурычы бар. Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры урынбасары Алексей Фролов әйтүенчә, газ өчен генә дә 229 миллион сум әҗәт җыелган. Ут өчен 41 миллион сум акча түлисе бар. Шунысын да искәрткәннәр: соңгы бер ел эчендә ут өчен әҗәт күләме 13 миллион сумга кимегән.

– 1 июльгә алынган саннарга караганда, идарәче оешмаларның «Татэнерго»га җылылык өчен 188 миллион сум бурычы бар, – ди Алексей Фролов.

Ел башыннан бирле Татарстанда коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне җыю күрсәткече



Илдар Мөхәммәтҗанов

97,9 процент тәшкил иткән. Суд приставлары федераль хезмәтенең республикадагы идарәсе хәбәр итүенчә, быел суд приставлары ваемсыз милекчеләрдән 375 миллион сум бурычны кире кайтарган.

Росстат мәгълүматларыннан күренгәнчә, агымдагы елның беренче чирегендә илдә яшәүчеләрнең коммуналь хезмәтләр өчен 876,4 миллиард сум әҗәте җыелган. Бер ел эчендә ул 72 миллиард сумга арткан.

– Бер түләгән кеше «счет-фактура» кәгазе килүгә үк түли, ә менә киребеткәннәрне нишләтсәң дә юк, – ди башкаладагы идарәче оешмаларның берсендә хисапчы булып эшләүче Гөлфия Булатова. – Хәтерләсәгез, берара мондый бурычлыларның исемлеген күпфатирлы йорт диварына элеп куя башлаган идек. Тик шул рәвешле күршеләре алдында оятка калучылар, әҗәтне каплау урынына, безнең өстән шикаятьләр яза башлады. Нәтиҗәдә Роскомнадзор моны кеше турындагы шәхси мәгълүматны тарату дип тапты һәм бу эшне тыйды. Бурычларны түләргә кирәклеген гади генә итеп ничек аңлатырга соң? Гел суд юлын таптарга туры килә.

Икътисад белгече Илдус Сафиуллин әйтүенчә, коммуналь хезмәтләр өчен бурычлылар саны арту халыкның матди хәле начараюга да бәйле.

– Хәтерләсәгез, былтыр әлеге төр түләүләрне бер ел эчендә ике тапкыр арттырып куйдылар да, нәтиҗәдә ут һәм су бәясе 20 процентка диярлек кыйммәтләнде. Тик моңа карап кына хезмәт хакы артмады бит. Дөньяда барган хәлләргә бәйле рәвештә, халыкның керем дәрәҗәсе, киресенчә, кимеде дә әле. Үзебездә үк үсә торган карабодайның бер килосы 90 сум тирәсе тора. Шуңа күрә коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә субсидия алучылар исемлеген зурайтырга кирәк дип саныйм, – ди белгеч.

Идарәче оешмаларның намуслылыгыннан шикләнүчеләр дә бар. Россия Дәүләт Думасының Төзелеш һәм ТКХ комитеты әгъзасы Александр Якубовский әйтүенчә, халык түләгән акча идарәче компания белән ут яки җылылык бирүче оешма арасында да «югалырга» мөмкин. Шуңа күрә алга таба коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне махсус исәп-хисап счетында җыеп бара башламакчылар. Идарәче компанияләр андагы акчаны фәкать чимал белән тәэмин итүче оешмаларга гына күчерә алачак, дип фаразлана.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КОММУНАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР ӨЧЕН ТҮЛӘҮДӘ КЕМНӘРГӘ СУБСИДИЯ ТИЕШ?

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, федераль ташламага ия булучылар, ягъни Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидлар, инвалид бала тәрбияләүче гаиләләр мондый хокуктан файдалана ала. Төбәк дәрәҗәсендә ташламага ия булучыларга хезмәт ветераннары, реабилитацияләнгән, репрессияләнгән гражданнар һәм күпбалалы гаиләләр керә. Андыйларга ташлама күләме, ярдәм чараларын алучыларның категориясенә карап, 30–50 процент тәшкил итә.

РФ Торак кодексының 159 нчы маддәсе нигезендә, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә бәйле чыгымнар гаиләнең уртак кеременең билгеле бер чигеннән артып китсә (ә Татарстанда әлеге күрсәткеч 21 процент тәшкил итә), әлеге гаилә аз керемле булып санала һәм субсидиягә өмет итә ала. Субсидия күләме һәр гаилә өчен аерым билгеләнә. Ул торак мәйданы, гаиләдәге кеше санына, кулланылган коммуналь хезмәтләр күләменә бәйле. Татарстанда субсидиянең уртача күләме 900 сумнан 1 мең 200 сумга кадәр тәшкил итә.

Авыл капкасы

Алдынгылык сере

Нурлат

Күпчелек район игенчеләре урып-җыюга узган атнада гына ныклап торып керешсәләр, фермер Нәсимә Камалова бөртекле культураларның уңышын җыеп та өлгергән инде. Иген кырларында апрельдән башлап бер тапкыр гына яңгыр явып узуны искә алсак, нәтиҗә куандырырлык. Уңышның сере нидә? Бу хакта фермерның үзеннән сорадык.

Хәзерге вакытта Нәсимә Камалованың чәчүлек мәйданнары 700 гектарны тәшкил итә. Шуның 155 гектары – бөртекле культуралар.

– Без уракка 22 июльдә төшкән идек, биш көн эчендә тәмамладык та, – ди ул. – Кырларыбызда ике комбайн эшләде. Бодай гектарыннан 30 центнер чыкты. Кайбер кырларда 40 гектарга кадәр дә җитте. Арыш гектарыннан 28 центнер чыкты. Бер мәртәбә яуган яңгыр белән үскән икмәгебез бу. Шуңа да карамастан, без уңыштан канәгать.

Фермер сүзләренчә, узган ел алар арыштан гектарыннан 33 центнер уңыш җыеп алганнар.

– Быелгы уңышның сере – биопрепаратларда, – ди ул. – Хуҗалык булдыру максатының берсе – табыш алу гына түгел, ә экологик яктан чиста продукция үстерү дә иде. Без туфракка микробиологик ашламалар аз кертәбез. Шуңа күрә безнең ашлык экологик яктан чиста. Икенчедән, мондый ашлама кулланып үстерелгән ашлыкның үзкыйммәте югары түгел, сыйфаты яхшы.

«Быел эшне иртә башлап, тиз тәмамлауның да төп сере шул биологик препаратларда», – ди Нәсимә ханым. Беренчедән, алар үсемлекнең үсү фазаларын тизрәк уздырып, ашлыкны алданрак өлгертә. Икенчедән, әлеге биопрепаратлар туфрактагы дымны сакларга ярдәм итә.

– Без инде бу ысул белән 4–5 ел эшлибез, – ди ул. – Бөртекле культуралардан тыш, без көнбагыш та чәчәбез. Гомумән, эш уңышлы булсын өчен, һәр нәрсәне вакытында эшләп барырга кирәк. Чәчүнең дә тоткарлыкларсыз узуы, симәнәләрнең дә отышлы булуы, техникаларның да ватылмыйча эшләве кирәк. Авыл хуҗалыгында һәр этап бик мөһим.

Нәсимә Камалованың төп яшәү һәм керем чыганагы авылда булса да, яшәгән урыны – Казан. Шуңа күрә фермер бары тик игенчелек белән генә шөгыльләнә.

– Ирем һәм кызым белән Казанда яшибез. Җәен авылга барыпкайтып кына йөрибез. Казанны яратам мин. Шушында туып-үстем, туганнарым биредә. Шуңа күрә әлегә авылга күченү теләге юк, – ди Нәсимә Камалова.

Аның сүзләренчә, эш җәелдерер өчен авыл хуҗалыгы җирләре генә җитеп бетми.

– Әлегә булган кадәрендә нәтиҗәле эшләргә тырышам. Чөнки җирне табу җиңел түгел. Мин башта Аксубай районында эшләдем, 2017 елда Нурлат районында җирләр алдым. Җир каян таптык, эшне шунда башладык инде. 20–25 ел элек бу җирләрдә хәтта уңышлы елларда да гектарыннан 17 центнер уңыш ала алмадылар, дип әйтүчеләр бар. Ә без менә чагыштырмача авыр елда да яхшы гына уңыш алуга ирештек, – диде Нәсимә Камалова.

Нурлат районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ирек Шәрәфетдинов сүзләренчә, бүгенгә барлык чәчүлек мәйданнарының 27 процентында эшләр тәмамланган. Уңыш гектарыннан 32,3 центнер чыга.

– Без нәтиҗәдән канәгать. Моның кадәр уңыш көтмәгән дә идек хәтта. Әйтик, Әхтәм Сөләйманов фермер хуҗалыгында гектарыннан уртача 40 центнер уңыш тәшкил итә. Көзге бодай – 46,3 центнер. Булган ашлыкны вакытында җыеп алып бетерергә тырышабыз, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Әтиле буласы килгәч...

Канлы сугыш, күз яшьле чорга туры килде безнең балачак. Ачлыкны да, ялангачлыкны да күп күрдек. Әтиләребез яу кырында ятып калгач, әниләребез – тол хатын, без әтисез балалар исемен күтәреп, шактый гына кыерсыту, кимсетүләр дә күреп үстек. Әтисезләр яклаучысыз, әтиләләр горур, масаючаннар. Шулай булмыйча, аларның әтиләре немецны дөмбәсләп, җиңеп кайткан бит. Җиңеп! Арада шундыйлары бар: тик торганда сиңа сугып, бәреп китәләр. Чана шуарга тауга киләбез, чананы йолкып алып, үзләре шуалар. Алар безнең шикелле ямаулы бишмәт кимәгән, аякларында – әтиләре итеге, өсләрендә – шинельдән тегелгән пиджак. Безне, хәерче дип, мыскылларга да күп сорамыйлар, аларның тамаклары тук, күңелләре көр, без – койты-йолкышлар, боеклар, чырайларыбыз да ак кар төсле.

Без тауда бөтен урам балалары бергә шуабыз, олысы да, кечесе дә шул бер тауда. Әни миңа, каян акча юнәтептер, артына һәм як-якларына рәсемле фанера кадаклап ясалган җиңел, кечкенә чана алып кайткан. Без иптәш кызлар белән урамда бер-беребезне тартып кына йөри идек. Ә беркөнне, әнигә дә әйтмичә, үзем генә шул чананы тартып, тауга киттем. Мин килгәндә, берничә малай басып торалар иде. Килеп җитүем булды, шуларның берсе – миннән шактый зуррак малай чанамны тартып, алып утырды да шуып төшеп китте. Чананңы төшеп ал, дип кычкырды да йөгереп китеп барды. Елый-елый чанамны алырга йөгердем, ватык чанамны күреп, тагын да катырак елый башладым, ул арада калган малайлар да киткәннәр иде инде. Арттагы, ян-яктагы фанераларын эзләп табып җыйдым да, үкереп елап, өйгә кайтып кердем. Әнидән куркып елыйм, ә әни, ни булды икән дип, минем тавыштан үзе курыккан. Ярар, чана гына икән дип, мине ачуланмыйча калды. Чанам да әллә ни ватылмаган, чәчәкле фанералары гына коелган булып чыкты. Аны күрше бабай бик тиз рәтләп бирде.

Икенче сыйныфта укыйбыз. Хәрефләрне өйрәнеп, кыска хикәя, әкиятләрне беренче сыйныфта ук укыдык инде. Хәзер туган тел китабыннан озынрак, катлаулыракларын укыйбыз. Мин начар укымыйм, ләкин мактанырлык әйбәт тә түгел, җитмәсә, китабым да юк. Беркөнне дәресләрне Сәвия белән бергә хәзерләргә булдык. Алар якын гына, безнең бакча башында гына торалар. Бардым мин аларга. Сәвия ишегалдында уйнап йөри, әтисе дә шунда. Янына килгәч, мин дәресләремне хәзерләдем инде, диде, төксе генә итеп. Китабыңны биреп тор инде алайса, дигәч, мин синең белән уйнамыйм да, китабымны да бирмим, дип, кырт борылып, нидер эшләп торган әтисе янына китеп, аягыннан кочып алды һәм, күрдеңме, минем әтием бар, дигән сыман башын чөеп, миңа карап тора башлады. Аның шулай мактану, масаюы (горурлану түгел) минем яралы күңелемне телеп алды, тынсыз калдырды. Мин дә ничәдер секунд аларга карап тордым да елый-елый чыгып йөгердем.

И, безнең әтиле буласы килүләр!.. Үтеп киткән ирләр артыннан «әти» дип пышылдап кына эндәшеп калабыз. Безнең ятим җаннарыбызга шул да рәхәт булып китә иде. Әниләребез дә көттеләр аларны, гомер буе көттеләр. Кайтмадылар шул, хәтта каберләре дә билгесез.

Роза ШӘЙХЕТДИНОВА.
Арча районы Чөмә-Елга авылы

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рифат ҖАМАЛ

ШУЛ КҮЗЛӘРГӘ КАРАП

Шигырь язу – җиңел нәрсә,
– диләр, –
Булса ихлас әйтер сүзләрең.
Шигырь язып була
сүзләрсез дә,
Сөю белән тулса күзләрең.

Шул күзләргә карап укып була
«Сөям сине, бәгырем!»
– дигәнне.
Шул күзләргә карап
тыңлап була
Сиңа багышланган көйләрне.

Шул күзләргә карап күреп
була
Бу дөньяның бөтен ямен дә.
Шул күзләргә карап аңлап
була
Кешелекнең бөтен мәнен дә!..

КУАС ТӘМЕ

Быелгы эссе-кызу җәйдә халыкның ничек сусаганын бер Ходай гына белә инде. Шундый челләдә куас эчкән саен күз алдыма балачак килеп баса…

Алтмышынчы еллар башы. Алексеевск районының Вахитов исемендәге колхозында кызу урак өсте. Кыр тулы комбайн, дистәгә якын йөк машинасы ашлык ташый. Авылның барлык хатын-кызы, укытучыларга кадәр, ындыр табагында: кемдер кайтып җиткән машиналарны бушата (ул елларны авылда самосвал дигән техника юк иде әле), кемнәрдер кул белән әйләндереп, «Трейлер» дип аталган җил очыргыч белән ашлыкны чистарта. Башкалар киптерелгән ашлыкны кире йөк машинасына төяп, Чистай элеваторына озата. Шул ук вакытта киләсе язгы чәчү өчен орлык та салып куялар. Күп эш кул көче белән башкарыла иде шул ул елларны.

Кыскасы, җәмәгать, бу күренешне бүгенге заман яшьләре аңлап та, кинодан карап та ышанмас әле. Бу үзенә күрә бер бәйрәм дә кебек иде, чөнки кырлардан яңа уңыш кайта, халыкның мул яшисенә өмет арта! Ул елларны хезмәт хакы натураль түләнә: күпме хезмәт көне җыясың, шуңа карап, сиңа арыш яисә бодай бирәләр. Әле колхозның яшелчә бакчасыннан халыкка капчык-капчык кыяр биргәнне дә хәтерлим. Тик халык бүгенге кебек зарланмады, булганына шөкер дип көн күрде.

Ындыр табагындагы бу тамашаның үзенә күрә бер режиссеры бар – кладовщик (безнең авылда «келәтче» дә дияләр иде әле) Кәлим абый. Ул – минем әнинең энесе, кушаматы – «Знахарь», ә мин – 10 яшьлек малай, шунда буталып, Кәлим абыйга булышкалап йөрим, чөнки бирелә авылның бөтен тормыш үзәге кайный.

Менә беркөнне ындыр табагына тагын да күбрәк тузан туздырып, ГАЗ-69 машинасы килеп туктады. Көн инде кичке якка авышып бара торган чак, ләкин эш тукталмый, вак-төяк мотор гөрелтесе тынмый, биредә эшләүчеләр тавышы белән кушылып, нининдидер бер аңлатып бетерә алмаган музыка кебек, тирә-якка тарала. Машинадан ике ир-ат чыгып басты да, кулларын тирә-якка болгап, гәүдәләрен боргалап, физзарядка сыман нәрсә ясап алдылар. Шул арада кайдадыр югалып торган Кәлим абый ялт итеп болар каршында пәйда булды. Тазарак гәүдәлесе кул биреп күрешә дә сораулар яудыра башлады: күпме уңыш кайткан, гектарыннан ничә центнер чыга, кырда ничә комбайн эшли һәм башкалар. Кәлим абый тотлыкмыйча җавап бирә, зур ашлык гөшелләрен күрсәтеп йөри. Кунаклар һәр төркем янына килгән саен саф татарча исәнләшәләр, мактап та куялар. Бу процессиянең иң артында мин йөрим, миңа кызык, нинди зур начальниклар икәнлеген беләсе килә бит.

«Экскурсия» бетте сыман. Шунда олы начальник Кәлим абыйга көтелмәгән сорау бирмәсенме:

– Слушай, Кәлим дус, бигрәк эссегә китте әле, халыкның эчәсе килә торгандыр бит, бу мәсьәлә ничек хәл ителә соң?

– Әнә бер салкынча сарайда флягалар белән якындагы коедан гел свежий су алып торабыз, – диде Кәлим абый. – Әйдәгез, сезнең дә эчәсегез килә торгандыр. Ул аларны бераз читтәрәк, келәтләр артындагы подвалына чакырды. Кунаклар аның артыннан иярде.

Ул подвалда яңа суелган ит, көзен җыелган бал, май һәм башкасы саклана. Кышларын түшәменә кадәр күрше күлдән боз чабып тутыралар, шул җәй буе, бүгенгечә әйтсәк, «холодильник-рефрижератор» ролен уйный. Ә бер бүлмәсендә кечкенә генә такта өстәл, кулдан ясалган берничә табуретка бар. Биредә җылырак, чөнки ишеккә якын, ләкин барыбер озак утырып булмас иде. Кәлим абый кунакларны шунда алып төшеп китте, мин бер читтә басып калдым. Олылар алдында гел буталып йөрмәм бит инде, өстәвенә тегендә салкын да бит әле. Тик берничә минуттан подвалдан «Ирек, кая юкка чыктың әле, төш монда!» – дигән тавыш ишетелде. Кунаклар өстәл янында утыра. Кәлим абый өстәл өстендәге кырлы стаканнарга яртылаш кына «Чистай малае» салып чыкты. Бу вакытта туралган ит белән ипи өстәлгә менеп кунаклаган иде инде. «Ирек, бар тегеннән куас чыгар безгә», – диде Кәлим абый, миңа борылып та карамыйча. Тиз генә алюмин чүмечне флягага батырып алдым да кунаклар каршына чыгарып куйдым. Алар башта куасны эчеп бетерделәр, аннары олы кунак кулына стаканын алды:

– Ну, Кәлимулла иптәш, не подкачайте районны! Вахитовлылар гел алда бара бит, уңыш быел да мул күренә. Халык та сездә бик эшчән. Кстати, куасың да замечательный. Безнең Алексеевскида да, Чистайда да мондыйны таба алмассың. Так что, Кәлимулла дус, сезнең колхоз уңышлары өчен күтәрәбез инде!

«Чистай малае» бушагач, кунаклар ачык һавага чыктылар. Тагын бер тапкыр тирә-якны күзәттеләр дә машинада йоклап утырган шоферны уятып кайтып киттеләр. Ә без Кәлим абый белән кабат подвалга төшеп, өстәлне җыештырдык, кабат куас эчтек.

– Менә шулай, Ирек, хуҗа кешеләрне шулай каршы да алмыйча булмый бу дөньяда. Әнә күңелләре булып китте сыман, – диде ул һәм рәхәтләнеп көлеп куйды.

– Кемнәр иде соң болар? – дип сорамыйча булдыра алмадым, билгеле.

– Партиянең райком секретаре Рәфгат Фәйзуллович Сафиуллин. Толковый мужик, зря бәйләнә торган кеше түгел. Бик югары күтәрелергә мөмкин, диләр Әләски (безнең авыл халкы район үзәген әле бүген дә шулай атый сыман) халкы…

Дөрестән дә, Рәфгат Фәйзуллович Сафиуллин соңыннан бик югары үрләр яулады: Чистай районының башкарма комитет рәисе, «Татпотребсоюз» җитәкчесе (бар иде заманында шундый бай һәм көчле оешма), ТАССРның Югары Советы, СССРның халык депутаты һәм башкалар… Урыны оҗмахта булсын.

Ул чакта подвалдагы куас бу дөньяда иң тәмлесе булып тоелды миңа. Бәлки шулай булгандыр да. Бүген кайсын гына эчсәм дә, теге вакыттагы Кәлим абый подвалындагы кебек түгел шикелле…

Ирек ХИСАМИЕВ

Яшьлек хатирәләре

Йөрәктән чыккан – йөрәккә

Татар телендә тапшырулар алып баручы радиоларыбызның берсендә элеккеге диктор Фоат Галимуллин белән әңгәмә булды. Бик сагынган идем инде аның тавышын. Бөтен эшемне ташлап, рәхәтләнеп тыңлап утырдым. Аның тавышының аһәңе бөтен тәнгә тарала, ял иттерә. Шулай ук Камал Саттарова, Мәрьям Арсланова, Айрат Арсланов, Эльс Гаделев сөйләгәннәрне дә бирелеп тыңлый идем. Фоат абый белән әңгәмә барышында хәзерге җырчылар турында сүз чыккач, «Бар матур итеп җырлаучылар, бар мәгънәсез, бернигә кирәкми торганнары. Мин аларны тыңламыйм», – дип әйтеп салды, беркемгә дә ярарга тырышып сөйләмәде. Элеккеге дикторыбызның бу фикере дә күңелемә май булып ятты. Шулай, сәхнә ул теләсә ни кыланып, боргаланып-сыргаланып йөри торган урын түгел бит. Йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып җитә. Фоат абый да менә шуның белән алдыра иде. Элек тә сокланып тыңлый идем, хәзер чиксез сокланып тыңладым.

Мәйсәрә ХӘММӘДИЕВА.
Чаллы

Әнинең йоклаганын күрмәдем

Без – сугыш чоры балалары. Гаиләдә берсеннән-берсе кечкенә сигез бала, идәндә салам тутырылган зур матрас, тезелешеп, шунда йоклыйбыз. Кечкенәләрне әти белән әни куенында җылытып йоклата. Кышлар да бик суык булды, ягарга утын юк. Урлаган өчен законнар каты.

Төнлә салам чәлдерергә китә идек. Әни бәйләп бирә, без кар өстеннән сөйрәп алып кайтабыз. Саламны ишегалдына кертеп аткач, йокларга йөгерәбез. Әнием саламнарны кечкенә көлтәләргә бәйли. Иртән кеше торганчы мичкә ягарга кирәк. Чөнки аның төтене кара-кучкыл булып бөтен авылга тарала. Без иртән торуга, әни салам көлендә кайнар ризык та әзерли иде.

Беркайчан да әнинең йоклаганын күрмәдем. Ул бездән соң ята, без торганчы аяк өстендә иде.

Әни балаларга агач ботаклары сындырырга да рөхсәт итмәде. «Себер җибәрерләр», – дип куркытты.

Гөлсияр ХИСАМОВА

Марияле дә, Санияле дә

Мария исемле уңган-булган чибәр кыз урман кисүче ир-атларга аш-су әзерләүче итеп билгеләнгән була. Урман кисүчеләрнең байтагы – Арча районыннан. Тимерхан исемлесе араларында күзгә иң күренеп торганы була: озын буйлы, киң күкрәкле, уен-көлкегә дә оста. Беренче көннәрдән үк ул Мариянең игътибарын яуларга тырыша. Мария дә моны абайлый, әлбәттә, бу хәл башкаларга да сизелә, «Ул бит башка диннән, эшне зурга җибәрә күрмә», – дип киңәш бирүчеләр дә табыла. Әмма яшьлек үзенекен итә, мәхәббәт уты дөрләгәннән-дөрли генә. Бергә булу турында фикергә дә киленә, әмма ике яктан да әти-әни моны кабул итә алмый. Яшь пар авыл белән янәшә бистәдә фатирга кереп яши башлый. Балалары туа. Тимерхан сабыйны күрше авыл мулласына алып барып, Сания дип исем куштырып кайта.

Күп тә үтми Тимерханга хәрби комиссариаттан повестка килә, ул сугышка алына. Әсирлеккә эләгә. Мария, авырып, хастаханәдә ятканда, Тимерхан авылга кайтып төшә. «Мин сезне ятратканга исән калдым, Марияне һәм кызым Санияне яратуым яшәтә мине, – ди ул авылдашларына. – Кызымның «әти» дип дәшүен ишетәсем килде. Күпләргә мондый бәхет тәтемәде, бик күпләр яу кырында, әсирлектә башын салды.

Тимерхан белән Мария кабат очрашулары белән бәхетле иде.

Дәлфирә ГАЛИМОВА

БЕР ИСТӘЛЕК

Минем беренче рәсемем «Ватаным Татарстан» газетасында 1989 елда басылды. Ул вакытта анда рәссам булып талантлы егет Зөфәр Хәкимов эшли иде. Күп сөйләшми, кырыс кына йөзле, сиңа бер карап ала да, кулларын гәүдә буенча йөртеп, кайсы җирең авыртканын әйтеп бирә. Сөйләшә башласаң, гади, кызыклы әңгәмәдәшкә әйләнә.

«Ватаным Татарстан»нан ул «Сабантуй» газетасына күчте. Аннан «Мирас» журналына эшкә урнашты. Зөфәр киткәч, «Сабантуй» газетасына рәссам таба алмыйча аптырадылар. Чөнки балалар газетасында сабыйларның күңелен аңлый ала торган нечкә күңелле, ювелир талант кирәк иде шул. Ә менә «Мирас» журналына күчкәч, Зөфәр халкыбыз тарихына багышланган искиткеч матур рәсемнәр иҗат итте.

Мин «Ватаным Татарстан»га эшкә килгәндә, анда инде Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илдус абый Рәхимов рәссам булып эшли иде. Мин аның күп ярдәмен күрдем, яхшылыклары тиде, аннан күп нәрсәгә өйрәндем. Ул типография эшләрен, китап, газета чыгару, аларны макетка салуның да бөтен серен белә. Иҗат бүлмәсендә тулы бер архив тупланган. Ул вакытларда газета рәссамы төрле рубрикаларга, мәкаләләргә, әдәби әсәрләргә, шигырьләргә рәсемнәр ясарга, беренче битеннән соңгы битенә кадәр бизәргә тиеш иде. Илдус абый бу эшләрне җиренә җиткереп, яратып, күңелен биреп башкарды. Бигрәк тә милләтебез тарихына багышланган әсәрләрне үз итте, бөтен сәләтен, осталыгын эшкә җикте.

Аның эш бүлмәсеннән язучылар, артистлар, иҗат әһелләре, рәссамнар өзелмәде. Айга бер-ике тапкыр ап-актан киенеп, ак мыеклары астыннан бераз гына елмаеп, рәссам-график Эрот Зарипов килеп чыга. Ул килсә, монда озак кына тоткарлана. Илдус абый белән сөйләшеп, серләшеп, аларның сүзләре бетми. Менә бервакыт коридорда берәүнең нәрсәдер сөйләп, шунда ук кычкырып көлгәне ишетелә. Бу рәссам Айдар Үтәгәнов булып чыга.

«Чаян» журналының баш рәссамы Таһир Фәизов та Илдус абый янында еш була. Бу атнада газетада юмор-сатира сәхифәсе чыга икән, шуңа күп итеп карикатуралар, шаян рәсемнәр алып килгән. Алар озак сөйләшмиләр, Таһир абый һәрвакыт кая булса да ашыга, ул шунда ук чыгып та китә. Ул да түгел, рәссам бүлмәсе янында җил-җил атлап, «нәни гигант, тере Тукай» шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов пәйда була. Янында дусты Наис Гамбәр дә бар. Наис абый кара күзлек киеп йөрде, мин аннан нигәдер шүрли идем.

Икенче көнне карыйм: Илдус абый янында, башын иеп, шагыйрь Эдуард Мостафин утыра. Илдус абый янына килеп, ул күңеленә тынычлык, эчен бушатырдай әңгәмәдәш таба иде. Шул арада каяндыр, ялт итеп, язучы Әхәт Сафиуллин килеп

Сулдан уңга: Илдус Рәхимов, Раушан Шәмсетдинов, Харис Якупов, Эрот Зарипов, язучы, дәүләт эшлеклесе Әнәс Хәсәнов.

чыга, аңа тиз генә яңа чыгачак китабының тышлыгын ясарга кирәк икән.

Бервакыт карыйм: лифт янында гөрелдәгән тавыш ишетелә: шагыйрь Госман Садә белән талант иясе Расих Шамский кереп килә икән. Расих Госман абыйга яңа язган шигырьләрен укый. Аларга Мөшәрәф Галиевнең дә тавышы кушыла. Айрат Садыйк белән Рафис Гыйззәтуллинның күзләре Расихта, мөлаем елмаялар, аннан ниндидер бер кызык сүз көтәләр. Расихка шул гына кирәк тә, атлаган саен шигырь чыгара, Салават булып та сөйләп күрсәтә.

Баш редактор урынбасары Миргалим абый Харисовны Илдус абый, зурлап, «Мир Галим» дип йөртте. Атаклы щепкинчыларның берсе, язучы, журналист, актер Миргалим абый Харисов та күптән безнең арада юк инде.

Мин гомерем буе остазларым, рәссамнар Илдус Рәхимов, Зөфәр Хәкимов иҗатларына сокланып яшәдем, алардан гел нәрсәдер өйрәнергә тырыштым.

Инде менә 80 яше тулар алдыннан Илдус абый да озакка сузылган каты авырудан соң вафат булды. Газетада бергә эшләгән хезмәттәшләремнең барысын да сагынып искә алам, алар алдында чал башымны иям.

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН

ШИГЪРИ ХӘТЕР

Безнең Тымытык авылы җырларда җырлана торган гүзәл Ык елгасы буенда урнашкан. Елганың икенче ягында Башкорт мәмләкәте башлана. Ык елгасы буйлап бик матур әрәмәлекләр сузылып китә.

Яз җиткәч, Ык буена киек кошлар кайтып, оя корып, балалар үстерәләр, чөнки Ык суында елга транспорты йөзмәгәнлектән, табигый чисталыгы сакланган. Тирә-як районнардан һәм шәһәрләрдән балыкчылар балык тотып, табигатьнең матурлыгы белән хозурланып, ял итәргә киләләр. Ык буеның уңдырышлы җирләре игеннәрдән югары уңыш алырга, тырыш авыл халкына мул яшәргә мөмкинлек тудыра.

1960 нчы елларда Азнакай районының «Авангард» колхозы җитәкчесе булып Ленин ордены кавалеры Газизулла Кәрамуллин эшләде. 1964 елда КПСС ҮК беренче секретаре Н.С. Хрущев «Авангард» колхозына килеп, мул уңыш үстерүче колхозчылар белән сөйләшеп, аларны бүләкләп китүе дә хәтердә.

Шул елларда Г.Тукай бүләге иясе, язучы Мәхмүт Хәсәнов Ык буена балык тотарга килә иде. Аяз Гыйләҗев, Сибгат Хәким, Хәсән Туфанның килеп кунганы хәтердә. Тымытык урта мәктәбенә килеп, бик эчтәлекле очрашулар да оештырды алар.

Индус ФАЗЛЫЕВ.
Азнакай районы

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юллагыз әле. Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга да соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

БИЗӘКЛЕ КАЕННАР ИЛЕНДӘ

Туган ил буйлап

Ишеткәнегез бармы икән: бары тик Карелия каенын эшкәрткәндә генә агач өслегендә искитмәле бизәкләр пәйда була. Тагын да тирәнгәрәк төшсәк, Россиянең атаклы зәркәнчесе Фаберже шул агачтан патшага пасха йомыркасы ясаган. Кызыклы мәгълүмат бу. Меңнәрчә күлләр, елгалар һәм шарлавыклар иленә юл тотканда, без монысын да истән чыгармадык.

Фаҗигале язмыш

Бай да, фаҗигале дә язмышка дучар ителгән төбәк икән ул Карелия. Чиктә булганлыктан һәм төрле дәүләтләрнең урманга, суга, файдалы казылмаларга бай бу җирләрне эләктерү өчен каны кызып торганлыктан, биредә совет хакимияте дә җиңел генә урнаша алмый. Кызыллар һәм аклар арасында барган бәрелешләргә Антанта гаскәрләре һәм финнар килеп кушыла. Соңгылары гомер-гомергә Карелиянең төньяк өлешен аерып алу уе белән яшәсә, җирле халык та үз милкен тартып алуга риза булып, кул кушырып утырмый. Советлар җиңгәннән соң да әле, безнең яклардагы сәнәкчеләр күтәрелеше кебек үк, монда да 1921 елда восстание булып ала. Әмма ул корал белән бастырылып, көчле репрессияләр аша күмәкләштерү чоры башлана. 1923 елда, ниһаять, Карелия Республикасы оеша.

Әмма шул географик урыны аркасында бер гасырда да мондагы халыкка тыныч кына яшәргә ирек бирмиләр. 1939 елда Финляндия белән Россия арасында шул җирләр өчен Кышкы сугыш булып ала. Ул чакта бәрелеш безнекеләрнең җиңүе белән тәмамланса да, 1941 елдан 1944 елга кадәр Петрозаводскида һәм аның тирә-юнендә фашистлар Германиясенең союзнигы саналган финнар хакимлеге урнаша. Ә холык-фигыле белән тыныч җирле фин-угор халкы, кайсы тарафка бил бөгәргә белмичә, әле Финляндия, әле Швециягә, әле Россиягә күчеп йөри. Википедиядә төрле көчләрнең ул чордагы бәрелешләрендә ун меңнәрчә кеше һәлак булган дип язылган.

Татар рухы

Карелия илен Россия карамагында саклап калу өчен, 1939–1940 елларда финнар белән Кышкы сугышта безнең дә күп кенә милләттәшләребез үз гомерләрен корбан иткән. Алар, нигездә, ТАССР Югары Советы Президиумы исемендәге 86 нчы укчы дивизия составында сугышкан. Карелия төбәгендә барган канкойгыч сугышлар турындагы язмаларның авторлары ул елларда бу якларда бер адым исән җир калмавын язалар. Менә шул җимереклекләрне төзәтергә бик күп эшче көчләр кирәк булып чыккач, аның өчен Россиянең үзәк районнарында һәм Идел буенда яшәүчеләрне оешкан төстә күчерү башлана. Узган йөзьеллыкның илленче елларында биредәге урман әзерләү хуҗалыкларына вербовка белән Татарстан АССРдан да күп кенә гаиләләр җибәрелә. Ә 1960–1970 нче елларда бирегә СССРның төрле төбәкләреннән, шул исәптән бездән дә техникум һәм вузларны тәмамлаучылар эшкә билгеләнү буенча белгеч буларак киләләр. 1980 нче елларда безнекеләр Костомукша шәһәре һәм шундагы тау-руда комбинаты төзелешендә эшли. Хәзерге вакытта татарлар Костомукша һәм Петрозаводск шәһәр округларында, Питкярант, Сортаваль, Суояр районнарында оешып яшиләр. Карелиядә көн күрүче 150дән артык милләт арасында татарлар сан ягыннан сигезенче урында тора.

Карелиядәге якташларыбыз хәзергәчә үзләренең татарлыкларын җуймаган. Алар рухи тормышларын «Чулпан» татар мәдәни җәмгыятенең Карелия төбәк оешмасы эшчәнлеге кысасында алып бара. Сабан туе үткәрүне дә, Татарстаннан иҗат коллективларын кабул итүне дә шулар оештыра. Карелия Республикасы белән Татарстан Республикасы арасында төзелгән сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль, мәдәни хезмәттәшлек турында 2014 елгы килешү милләттәшләребезнең активлыгын тагын да арттыруга китергән. 2015 елда Красный Бор һәм Сандорм авыллары чигендәге бушлыкка 1938 елларда бу төбәктәге ГУЛАГ лагерьларына репрессияләнеп китерелеп, һәлак ителгән татарларга һәйкәл куелу да – шуның нәтиҗәсе.

Табигать һәйкәлләре

Шунысы куаныч: сугыш фаҗигаләре тезмәсеннән гыйбарәт булган тарихы да, ГУЛАГка бәйле кара таплары да Карелиянең искиткеч табигатенә зыян сала алмаган. Карелия юнәлешендә иң кызыксындырганы «Кижи» музей-тыюлыгы булды. «Рускеала» – таш чыгару мәгарәләреннән барлыкка килгән табигать һәйкәле. Санкт-Петербургның зиннәтле сарайлары һәм храмнары өчен мәрмәр таш шуннан алынган. Карелиянең үз вулканы да булган. Авызына су тулып, ул күлгә әверелгән, аның тирә-ягы урман белән капланган. «А зори здесь тихие» фильмының яңартылган ремейк вариантының шунда төшерелгәнлеге дә мәгълүм булды безгә.

Карелиядә шунысы шәп: аның кайсы районына гына барып чыкма, турист өчен кызыклы берәр объект очратасың. Әмма шаккатмалы табигатькә ия булган җирләрнең төп халкы – саам турында сүз кузгатмасак, Карелия каенының серен чишмәсәк, дөрес булмас. Урман саамнарының тылсымчысы Талви Укко белән очрашмасак та, борынгы кешеләр яшәгән киез тирмәне күрергә дә, аның уртасындагы учак янында җылынып утырырга да насыйп булды.

Ә Карелия каеннарына килгәндә, эшкәрткәч, соклангыч бизәкләре пәйда була торган шушы агачны борынгы рус дәүләтендә җирле халыктан ясак итеп җыйганнар. Узган гасырның баш-баштак туксанынчы елларында Финляндиягә сата торгач, аларның саны бүгенгә өч мең тирәсе генә калган. Карелиянең биология галимнәре хәзер бу каенны теплица шартларында үрчетү һәм гади каенга ялгау юлы белән аның клонын алу өстендә эшлиләр.

Гүзәл ӘХМӘТҖАНОВА

Саклык сорала

Татарстанда җенси юл белән күчә торган йогышлы авырулар йоктыручылар саны арткан. Белгечләр шулай дип кисәтә. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе мәгълүматларына караганда, ел башыннан бирле республикада барлыгы 429 кеше ВИЧ йоктырган. Бу, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 7,9 процентка күбрәк.

Әгерҗе, Азнакай, Бөгелмә, Алабуга, Лениногорск, Яңа Чишмә, Сарман һәм Ютазы районнарында чир йоктыручылар саны аеруча күп теркәлгән. Ә менә Әлки, Апас, Югары Ослан, Чүпрәле, Питрәч, Балык Бистәсе, Теләче районнарында андый бер очрак та ачыкланмаган.

Республика СПИД һәм йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш үзәгенең баш табибы Нияз Галиуллин сүзләренә караганда, бүген Татарстанда ВИЧ инфекцияле 15210 кеше исәптә тора. «Эпидемиологик вазгыять тотрыклы кала. Дөрес, ярты еллык саннарда бераз арту күзәтелде. Әмма әлегә ахыргы саннар турында сөйләргә иртәрәк», – ди ул.

ВИЧ, гадәттә, җенси мөнәсәбәтләр вакытында да, кан аша да йога. Ул ана сөте аша балага да күчә ала. Күрешү, кочаклашу, үбешү вакытында исә аны эләктереп булмый. Шуңа күрә белгечләр ВИЧтан саклану өчен иң элек очраклы җенси мөнәсәбәтләрдән сакланырга, стериль кораллар кулланылмый торган шикле урыннарда татуировка, пирсинг яки тире катламын боза торган башка процедуралар ясатмаска киңәш итә. Башка кешенең шәхси гигиена әйберләреннән (кырыну станогы, теш щеткасы, кайчы) файдалану да тыела. Даими рәвештә ВИЧка тест тапшырып, тикшеренеп тору да комачауламас, ди алар.

ВИЧ белән янәшә йөрүче тагын бер йогышлы чир – сифилиска бәйле вазгыять тә мактанырлык түгел. Республика клиник тире-венерология диспансерының баш табиб урынбасары Гүзәл Вафина китергән саннардан аңлашылганча, быелның алты аенда республикада сифилис йоктыручылар саны 32,5 процентка арткан.

– Әлеге чир күбрәк безгә эшләргә килгән мигрантлар арасында очрый. Алар тик торганда хастаханәгә бармый, билгеле. Шуңа күрә алар янына үзебез барабыз, – ди белгеч.

Җенси юл белән күчүче әлеге инфекция кешенең тән тиресен, нерв системасын, эчке органнарын зарарлый. Әмма, ВИЧтан аермалы буларак, сифилис кешедән-кешегә кашык-тәлинкә кебек көндәлек кирәк-яраклар аша да йогарга мөмкин. Шуңа күрә, йогышлы авыруларны вакытында ачыклау өчен, хатын-кызларга даими рәвештә – гинекологка, ирләргә урологка барырга кирәк, ди белгечләр. В гепатитына һәм сифилиска тест та бирергә киңәш итә алар.

Белеп тор!

ВИЧКА КАЙЛАРДА ТИКШЕРЕНЕП БУЛА?
✓Казанда: Ершов урамы, 65 йорт.
✓Чаллыда: Вахитов проспекты, 12 йорт.
✓Әлмәттә: Түбән Мактама бистәсе, Промышленная урамы, 1а йорт.
Тулырак мәгълүмат өчен ышаныч телефоны:
8 (843) 272 70 90.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Кушымта

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Красносельский авыл җирлеге, кадастр кварталы номеры 16:16:081601, 06.03.2023 ел № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә, комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Совет ур., 13 й. (телефон: +7 (84365) 2-35-85) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (Комплекслы кадастр эшләре заказчысы) (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органы – https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (кадастр учеты органы – https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Аларга карата 16:16:081601 кадастр кварталы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 28 августында (14 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Совет ур., 13 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 28 июленнән 2023 елның 28 августына кадәр һәм 2023 елның 28 августыннан 2023 елның 2 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шулай ук фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта-планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Әлеге каршы килүләргә аларны җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдыруда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче (билгеләгән документлар булганда) кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Кушымта

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге, кадастр кварталы номеры 16:16:211801, 06.03.2023 ел, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә, комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге, Верхняя ур., 99А й. (телефон: +7 (84365) 32-9-63) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (Комплекслы кадастр эшләре заказчысы) (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органы – https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (кадастр учеты органы – https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Аларга карата 16:16:211801 кадастр кварталы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлеге чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 29 августында (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге, Верхняя ур., 99А й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 29 июленнән 2023 елның 29 августына кадәр һәм 2023 елның 29 августыннан 2023 елның 3 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шулай ук фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта-планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Әлеге каршы килүләргә аларны җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдыруда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче (билгеләгән документлар булганда) кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Кушымта

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлеге, кадастр номерлар кварталлары 16:16:190701, 16:16:082101, 06.03.2023 ел, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә, комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау ав., Юбилей ур., 1А й.,1000 бүлмә (телефон: +7 (84365) 74-7-79) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (Комплекслы кадастр эшләре заказчысы) (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (үз территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органы – https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (кадастр учеты органы – https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Аларга карата 16:16:190701, 16:16:082101 кадастр кварталлары территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 28 августында (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау ав., Юбилей ур., 1А й., 1000 бүлмә.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 28 июленнән 2023 елның 28 августына кадәр һәм 2023 елның 28 августыннан 2023 елның 2 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шулай ук фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Әлеге каршы килүләргә аларны җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдыруда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче (билгеләгән документлар булганда) кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Кушымта

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Чернышевка авыл җирлеге, кадастр кварталы номеры 16:16:321201, 06.03.2023 ел, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә, комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Чернышевка авыл җирлеге, Клуб ур., 1 й. (телефон: +7 (84365) 73-5-05) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (Комплекслы кадастр эшләре заказчысы) (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органы – https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (кадастр учеты органы – https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Аларга карата 16:16:321201 кадастр кварталы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җир кишәрлеге чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 29 августында (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Чернышевка авыл җирлеге, Клуб ур., 1 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 29 июленнән 2023 елның 29 августына кадәр һәм 2023 елның 29 августыннан 2023 елның 3 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә һәм әлеге каршы килүне җибәргән зат турында мәгълүматларны, шулай ук фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булганда), шулай ук милекче адресын һәм (яки) милекченең электрон адресын, шәхесен раслаучы документы реквизитларын, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны белән килешмәве сәбәпләре нигезләнешен, җир кишәрлегенең кадастр номерын (булганда) яки территориянең карта планы проекты нигезендә җир кишәрлеге билгеләнешен үз эченә ала. Әлеге каршы килүләргә аларны җибәргән затның мондый җир кишәрлегенә хокукын раслаучы документлар күчермәләре яки мондый җир кишәрлегенә хокукны билгеләүче яки раслаучы башка документлары, шулай ук мондый җир кишәрлеген булдыруда чикләрнең урнашу урынын билгеләүче (билгеләгән документлар булганда) кушып бирелергә тиеш.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

vk.com

КҮҢЕЛСЕЗ ЯЛ

Рөстәм Нигъмәтуллин исә тагын бер кат игътибарлы булуны сорады. Кисәтүләргә аеруча игътибар бирергә кушты ул.

– Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсенә килгән зыяннарны бетерергә кирәк. Йорт түбәләрен көнендә үк төзәтеп куярга өлгермәсәләр дә, аны тизрәк башкарырга кирәк. Әлегә тынычланырга ярамый. Дежур төркемнәр оештырып, һәрнәрсәгә әзер торыйк, – диде ул.

«Дөнья бетте, дигән идек»

Казанның Яңа Салмачы бистәсендә яшәүче Хәмдия Хәбибуллина да давыл шаһиты була. «Әллә каян килеп чыккан кара болыт берничә минут эчендә бар дөньяның астын өскә китерде», – ди ул.

> Вакытында чарасын күреп калдык. Безнең якта җил көчле булды. Гараж ишекләрен ике кеше бергә көчкә яптык. Тизрәк машиналарны тыныч урынга куйдык. Белгән догаларны укып, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорадык. Күршебезнең капкасы ауды. Машинасын ярый гаражына кертеп өлгерде, – ди ул.

Иске Салмачыда яшәүче Нәкыйп Сафин ишегалдына берәүләрнең теплицасы очып килеп утырган. «Аңышмый да калдык. Шундый матур, чалт аяз көн иде бит. Эсселек шулай итә инде ул. Башта кыздыра, аннан йә боз ява, йә давыл куба», – ди Нәкыйп.

Ул көнне Казанда яшәүче Чулпан Гарипова суга дип Раифага киткән була. Матур көнне бушка уздырасылары килми аларның. Кызы һәм дустының улы белән юлга кузгала.

– Машинага сулы шешәләрне урнаштыргач, кайтырга җыенган идек. Кинәт кенә кире уйладык, матур җирләр карап килергә булдык. Шунда шашлык пешерүчеләрне күреп, сыйланырга кердек. Менә шул коткарды безне. Шунда керүгә, давыл башланды. Кояш, эссе, матур көн. Машинада 39 градус җылы күрсәтә иде бит. Боз яварга тотынды. Аның җиргә төшүе була, асфальттан томан кебек пар күтәрелә. Мәхшәр иде андагы күренеш, – ди Чулпан Гарипова. – Бераз тынычлангач, кайтырга чыктык. Юлда бөке. Ике якта агачлар. Бик курыктык. Ул агачлар менә-менә машинага килеп төшәр төсле. Җитмәсә, юлга аркылы бер агач ауган иде. Шулкадәр төз, нык ул. Аны ирләр күтәреп читкә ташлады. Ничек күтәрә алганнардыр, дип аптырадым. Балалар курыкты инде. Алар гына түгел, үзем дә, исән генә кайтсак ярар иде, дип теләдем. Кызым бик елады. Җитмәсә, көчле итеп яшен яшьни. Бераз тынычланганчы дип, юл буендагы кибетләргә дә кереп торасым килде. Тик балалар, кайтыйк, диделәр. Шулкадәр озын юл булды ул.

Мари Эл Республикасындагы Яльчик ял итү базасында җырчы Дилә Нигъмәтуллинаның кызы Сәфинә белән ире Илсур да булган. «Гаиләбез белән шунда ял итәргә барган идек. Мин, ирем белән кызымны калдырып, эш белән Киров өлкәсенә киттем. Бераздан шомлы хәбәр таралды. Гаиләм янына кире кайтканда кичергән хисләремне белсәгез иде. Борчылудан акылдан язам дип торам. Илсур белән Сәфинә давыл вакытында калын агачны кочаклап торып котылганнар», – дип язган җырчы үзенең социаль челтәрдәге битендә.

«Ничек яшәргә?»

Котыла алмаучылар да бар. Һәлак булганнарның якыннары әйтүенчә, алар давыл чыгып, нидер булыр дип ялга китмәгән бит инде! Питрәч районының Көек авылында яшәүче Сәлимовларның апалары шулай ди. Гаилә шимбә көнен көтеп ала. Алар, бик шатланып, якын дуслары белән бергә юлга кузгалалар. Тик, ни кызганыч, палаткалары өстенә агач ава.

Гаилә башлыгы Ринат – авыр хәлдә, реанимациядә. Аны ясалма сулыш алу аппаратына тоташтырганнар. Ринатның хатыны – 32 яшьлек Гөлнара, 2 яше дә тулмаган кызы Ясминә, май аенда дөньяга килгән сабые София, өсләренә агач төшеп, шунда ук һәлак булалар. Фаҗига вакытында бөтен гаилә палаткада, ә Гөлнара кечкенә сабыен имезеп яткан була.

– Бик матур яшәделәр, – ди Сәлимовлар турында Ринатның апасы Фәридә. – Киленебез белән энем интернетта танышып өйләнешкән иде. Гөлнараны бик яраттык. Авыр сүз әйтә белми иде ул. Гомере генә кыска булган җаныемның. Киленебез Башкортстанныкы. Яшь чагында Казанга укырга килеп, монда яшәп калган иде. Казандагы бер институтта кадрлар бүлегендә эшләде. Алар башта «Салават Күпере»ндә фатир арендалап торды. Быел ипотекага Питрәч районының Көек бистәсеннән фатир алганнар иде.

Сәлимовлар туганнары белән дә, күршеләре белән дә дус яшиләр. Ялга да алар берничә гаилә бергә чыгып киткән. Алар киткән көнне Ринатның әнисе дә Көектә булган, балаларын ялга озатып калган. Ике тапкыр инсульт кичергән ананың үзенә дә, балалары белән булган хәлне ишеткәч, «ашыгыч ярдәм» чакыртырга туры килгән.

– Энем гаиләсе ялга киткәч, телефоннан фотоларын карап бардым. Бер мәлне берни куймый башладылар. Шул арада «Телеграм»га кереп чыгыйм дисәм, хәтәр давыл турында язганнар. Яльчик дигән сүзне күрүгә, беттем инде. Тизрәк энемә шалтырата башладым. Ул телефонын алмады. Гөлнараныкын тикшерүчеләр алды да бу ачы хәбәрне әйттеләр. Ничекләр яшәргә инде хәзер?! – дип өзгәләнә ул.

Яльчик күле буенда Татарстаннан 8 кеше, шул исәптән 3 баланың гомере өзелде.

Мари Эл башлыгы Юрий Зайцев атна азагында булган фаҗигадә зыян күргәннәргә матди ярдәм булачагын белдерде. Һәлак булганнарның гаиләләренә матди ярдәм 1 млн сумны тәшкил итәчәк. Зыян күрүчеләргә 50 меңнән 500 мең сумга кадәр акча бүлеп биреләчәк.

Саклангынны саклармын

Соңгы арада үзебез дә әллә нишләдек. Телефонга килгән кисәтү хәбәрләренә дә артык игътибар итми башладык. Янәсе, яумас әле, безгә килеп җитми ул. Соңгы вакыйгалар исә тагын бер кат сак булырга өйрәтте.

Татарстанның гидрометеоүзәге җитәкчесе Феликс Гоголь кисәтә: август аенда көчле давыл тагын кабатланырга мөмкин.

– Алдагы көннәрдә көтелмәсә дә, ай дәвамында мондый табигать күренешләре кабатланырга мөмкин. Җылы һава массасына салкыны өстәлсә, давыл була. 29 июль көнне килеп чыккан һәлакәтнең сәбәбе дә шул. Ул көнне Татарстанда ике атмосфера фронты кисеште. Республика аша салкын һәм эссе һава фронты узды. Мондый күренеш җәен еш күзәтелә, – ди ул.

КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы профессоры Юрий Переведенцев, Россия гидрометеоүзәге мәгълүматларына нигезләнеп, август башы эссе булачак, дип фаразлый.

– Бүген һава температурасы 25 градус булачак. Яңгырлар да булуы мөмкин. Иртәгә 29 градуска җитәчәк. 3 августта исә 31 градус эсселек көтелә. Давыл чыгу, яшенле яңгыр, боз явуны алдан әйтеп булмый. Бар да Татарстанда нинди циклон хакимлек итәсенә бәйле, – ди ул. – Әгәр антициклон килә икән, коры эсселек булачак. Юк икән, безгә яңгырлар килеп, һава температурасы төшәчәк.

Ярар, һава торышына колак салдың, ди. Ялга киткәндә тагын нишләргә кирәк соң? Баксаң, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы Баш идарәсе матбугат үзәге хәбәр итүенчә, үз җае белән ял итәргә баручылар (оештырылмаган ял турында сүз бара. – **Ред.**) бу хакта коткаручыларга алдан хәбәр итәргә тиеш икән. Каядыр ял итәргә җыенучылар иң элек үз төбәкләренең МЧС сайтына кереп теркәлергә тиеш. Алар онлайн гаризада кая барулары турында мәгълүмат калдыргач кына юлга чыксыннар иде, ди коткаручылар.

Ялга җыенучыларга киңәшләр

- Иң элек алдагы көннәргә нинди һава торышы буласын белешегез.
- Үзегез белән тиешле җайланмалар, җиһазлар, саклык чараларын алыгыз.

Көчле җил вакытында нишләргә?

- Якында бина булса, шунда керегез;
- балаларны караучысыз калдырмагыз;
- урамда булсагыз, җир асты юлларына яки бина подъездларында керегез;
- бу вакытта йорт диварлары янында яшеренергә кирәкми, чөнки түбәләрдән шифер һәм башка түбә материаллары төшәргә мөмкин. Шулай ук җәмәгать транспорты тукталышлары, төзелмәгән биналар янында ышыкланырга да ярамый;
- урамда реклама щитларыннан, элмә такталардан, юл билгеләреннән, электр линияләреннән ерак торырга кирәк;
- зур агачлар янында тормагыз. Агач астына машиналарыгызны куймагыз;
- электр линиясе астында тору һәм өзелгән электр чыбыкларына якынлашу бик куркыныч;
- өстегезгә тәрәзә пыялалары, түбә калайлары, йортны бизәгән элементлар килеп төшмәсен. Ул урыннан читкә китегез;
- йортларның барлык тәрәзәләрен нык итеп ябарга, балконнардан тышкы якка төшәргә мөмкин булган әйберләрне алып ташларга кирәк;
- торак яки эш бүлмәсендәге тәрәзәләр янына якын килмәгез.

Яшен вакытында нишләргә?

- Әгәр дә сез велосипедта яки мотоциклда барганда яшенле яңгыр астында калсагыз, һичшиксез, туктап торыгыз;
- машинада да барырга ярамый. Электроникасы бозылып, яшен сугу ихтималы зур;
- яшен вакытында ачык урында булсагыз, җиргә ятарга киңәш ителә. Суга керергә ярамый. Янәшәгездә күл, сулык булмасын. Су яшенне үзенә тарта;
- нинди генә бәла-каза булса да, «112» номерына шалтыратыгыз.

БАРЫСЫ ДА ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

Хәйрия

Татарстанда «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» хәйрия акциясе башланды. «Бердәм Россия» партиясенең төбәк иҗтимагый кабул итү бүлегендә Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова Казанда һәм Биектау районында яшәүче аз керемле һәм күпбалалы гаиләләргә букчалар тапшырды. 1 сентябрь күчтәнәчен башка район һәм шәһәрләр дә өләшә башладылар.

Әлеге акция Татарстанда 2007 елдан бирле уздырыла. Иганәчеләр, депутатлар аз керемле, күпбалалы, тәрбиягә алынган һәм авыру балаларга мәктәпкә җыенырга булыша. Шушы вакыт эчендә 237 меңнән артык укучыга барлыгы 333847570 сумлык ярдәм күрсәтелгән. Узган ел парта арасына тәүге тапкыр утырган 10 меңгә якын сабыйны сөендергәннәр. Луганск, Донецк республикаларыннан килгән 211 балага портфель, мәктәп формасы, аяк киеме һәм башка кирәк-ярак бирелгән. «Бердәм Россия»нең республикадагы төбәк бүлеге быел да Лисичанскидагы 1869 укучыны укырга хәстәрләргә булыша. Рубежное шәһәрендәге 700ләп балага шундый өлеш чыгачак. Махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук читтән күченеп килүче гаиләләр дә читтә калмый. Ярдәм 5682 мең балага тиячәк.

Сарман районында 86 укучыга портфельләр тапшырылачак. Мортышбаш авылында яшәүче күпбалалы Сөнгатуллиннар гаиләсенә дә эләгәчәк ул. Алар сигез баланы сыендырган. Моннан тыш, үзләренеке – дүртәү. Хәзерге вакытта балаларның бишесе – яннарында. Кирилл 1 нче сыйныфка барачак. Хәрефләр таный, иҗекләп укый белә икән. Диана – 4, Артур – 5, Артем 8 нче сыйныфка барырга җыена. 11 нче сыйныфны тәмамлаган Гөлназ тиздән Ижаудагы медицина уку йортына китәчәк. Ике балалары көллияттә һөнәр үзләштерә. Бер уллары армиядән кайткан. Калганнары үз гаиләләрен корган инде.

– Мондый ярдәмне беренче тапкыр гына алу түгел. Шактый балага бирелде ул. Балалар бик сөенә инде, сөенмичә?! Үзебез дә, букча эченә нәрсә тутырганнар икән, дип кызыксынып карыйбыз бит, – ди Люция апа. – Безгә хөкүмәт пособиесен биреп тора анысы. Хәлебез әйбәт. Бик авыр яшәгән гаиләләр бар бит. Алар өчен зур ярдәм инде бу. Узган ел бер баланы укырга әзерләү 25 мең сумга төште. Быел әлеге сумма гына җитмәс, шәт. Әле бер генә баланы киендердем. Калганнарына да форма алырга кирәк. Уку әсбаплары бигрәк кыйммәт. Дәфтәрнең иң арзаны 13 сум тора. Кирәкле әйберне бер кат алып куябыз да беткәннән беткәнгә сатып алабыз.

Казанда яшәүче Альбина Шакирҗанованың улы Илдус быел 4 нче сыйныфка бара. Баласын ялгыз үстерүче ана аз керемле гаилә булып саналса да зарланмый. Узган елдан калган, шулай ук кеше биргән киемнәрне киертергә җыена. Дәфтәр, каләмнәрне күптән сатып алган.

«Татар-информ»

– 1 нче сыйныфка барганда, портфель бүләк иткәннәр иде. Башка андый ярдәм булмады. Аны беренче сыйныфка баручы гаиләләргә генә бирәләр түгелме соң? Улым шул портфеле белән өч ел йөрде. Хәзер искерде инде, яңасы кирәк. Бирсәләр, баш тартмас идем. Акыллы кеше каршы килә димени? Кемдер ояла, мин юк. Бала өчен бит ул. Ярдәм итүчеләргә халык алдында рәхмәт әйтүнең дә бернинди авырлыгын күрмим, – ди Альбина.

Мөслим районында быел 1 нче сыйныфка 196 бала барыр дип фаразлана. «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» акциясе кысасында әлеге ярдәмне 140 бала алачак. Бу сан үзгәрергә дә мөмкин. Махсус хәрби операциядә катнашучы гаиләләргә дә өлеш чыгачак.

– Кемгәдер сертификат, кемгәдер портфель әзерлибез. Моны гаиләләргә уңайлы булсын өчен махсус эшләдек. Әти-әни теләсә кайсы вакытта үз җае белән кибеткә барып ала. Җитмәсә, акчасын өсти, – ди Мөслим районы башкарма комитет җитәкчесенең социаль эшләр буенча урынбасары Марина Бәдретдинова. – Бөтен кеше алдында биргәндә, бәлкем, читенсенү хисе дә булыр иде. Кибеткә барып алгач исә, аны бүләк итеп кабул итә.

Сан

Быел **1** нче сыйныфка **56999** укучы барачак.
1–4 сыйныфта барысы **226272** бала белем алачак.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАРИХКА СӘЯХӘТ

Яшәргә өйрәнәбез

Әлки районындагы Сихтермә авылы «коммунизм утравы» буларак билгеле. Хәтерләсәгез, әлеге авыл турында язганыбыз бар безнең. Әмма бу юлы сүзебез шушы «утрау»дагы «Яңа Сувар» тарихи-туристик комплекс турында булыр. Анда кунак булып, мәһабәт кирмәннәр артынданиләр барлыгын күреп кайттык без.

Автор коллажы

Тарих. Бу урында юктан гына шундый зур комплекс төзеп куярга уйламаганнар, билгеле. Культуролог Владимир Алмантай сүзләренә караганда, монда чуаш, Казан һәм керәшен татарларының бабалары ерак VI гасыр ахыры – VIII гасыр башында ук килеп төпләнгән.

– Монда күченгәнче Кавказ, Алтай якларында яшәгән алар. Шуңа да зороастризм мәдәниятен алып килгәннәр һәм 200–250 ел буе шуның белән яшәгәннәр. Соңрак Иран һәм Гыйрактан ислам дине килгән. Шулай итеп, бу якларга зороастризм язу алып килсә, ислам белән бергә тәңкә сугу, акча ясау килгән, – дип сөйләде Алмантай.

Бу әле – бүгенгәчә сузылган бай тарихның бер кыйпылчыгы гына. Тамырларыбызны оныттырмау һәм тарихыбызны барлау максатыннан, «Яңа Сувар» комплексында төрле чорларга карый торган корылмалар төзелә. Әйтик, тиздән ут храмы, рун алфавитына багышланган ташлар паркы, тәңкә сарае калкып чыгачак. Инде хәзердән үк монда ике төрле тегермән, тарихның төрле чорларына карый торган йортлар бар. Болар барысы да алты метрлы манаралы кирмән артында булачак. Кыскасы, бу урынны узып китәрмен, дип куркасы юк: таш кирмәннәр әллә кайдан ук чакырып торачак.

Тарихыбызның совет чоры белән кызыксынучылар өчен монда «СССРга 100 ел» паркы да бар. Дөньяда башка бер җирдә дә юк ул. Әлкидә бар менә. Минем ише XXI гасырда туган балалар өчен бу парк бөтенләй яңалык булыр кебек.

Ял. 53 гектарлы бу комплекста бүген аеруча популяр булган глэмпингларда да, кунакханәдә дә ял итү өчен шартлар бар. Рәт-рәт тезелеп киткән өч-алты кешелек буралы йортларда кер юу машинасына кадәр бар, дип сөйләде комплекс җитәкчесе Инна Лисина.

– Актив ял яратучылар өчен төрле шартлар тудырабыз. Әйтик, балык тоту. Безнең күлләрдә форель балыгына кадәр бар! Хайваннар дөньясын өйрәнергә теләүчеләр өчен кечкенә генә зоопарк та булдырдык. Әмма аны зоопарк дип атау дөрес булмас, бездә хайваннар читлектә түгел, үзләренә уңайлы булган мохиттә – урманда яши. Бу тирәләргә ашар өчен генә килә алар. Төньяк боланнары, мараллар, дөяләр... Өндә яши торган аюыбыз да булачак. Теләгән кеше җәен – атта, кышын боланда йөри ала, – дип санап китте ул.

Комплекс территориясендә күзебез төшкән тагын бер нәрсә – якут, бурят халыкларының традицион йортлары – чумнар. Теләгән кеше аларда да яши ала икән. Себердән махсус кайтартканнар үзләрен. Сауна, мунча, коену өчен зур себер мичкәләре – болары таныш инде, әмма умарта оясында йоклатуларын беренче ишетүем булды. «Ульетерапия» дип атала ул, сәламәтлеккә файдасы гаҗәеп көчле икән.

Болар барысы да – мөмкин кадәр күбрәк кеше җәлеп итү чаралары инде. Комплексның асылында мәдәният һәм тарих белән таныштыру ята.

– Гомумән, мондый комплекс төзү идеясе 2021 елда – Уяв бәйрәмен уздырырга әзерләнгән вакытта килде. Ул чакта ул чуаш үзәге буларак уйланылса, бүген без монда төрле милләтләрнең тарихларын берләштерергә тырышабыз. Теләсә кем ял итәрлек, кызыклы шөгыль табарлык булсын, – диде Инна Лисина.

«Яңа Сувар»дагы бәяләр

Кунакханәдә дә, аерым йортларда да бер кешегә тәүлегенә 1000 сум. Иртәнге аш – 150 сумнан. Мунча, сауна, себер мичкәләре өчен аерым түләү – 1000 сумнан. Һәр йорт янында шашлык пешерү өчен махсус урын бар. Анысы бушлай.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сораштыру

Күпме карасам да, карап туймыйм...

Кабартылган иреннәр, озын керфекләр, ясалма чәчләр... Безнең заманның матурлык стандартларын саный китсәң, күпчелеге ясалмага кайтып кала. Шулай булуына карамастан, Россиядә яшәүчеләрнең 66 проценты, табигый матурлык һәрвакыт күзне иркәләячәк, дип саный. «Авито Услуги» хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләре әнә шул хакта сөйли. Татар артистлары бу турыда ни уйлый икән?

Җәвит ШАКИРОВ, Татарстанның халык артисты:
– Ясалма матурлыкны, гомумән, ясалмалыкны яратмыйм. Үземнең беркайчан да сәхнәгә грим, чурт-чураман сылап чыкканым булмады. Зөлфиягә дә бизәнмәскә кушам, мин аны ничек бар, шулай яратам. Аның бүгенгә кадәр, шушы яшенә җитеп, битенә әллә нәрсәләр ясатканы юк. Үзе ясаган кремнар, маскалар сөртә. Экономичный! Чөнки ул болай да матур!

Гөлназ СӘФӘРОВА, Татарстанның атказанган артисты:
– Мин табигый матурлык яклы. Әгәр үзеңне 100 процентка кабул итәсең, үз-үзеңә ошыйсың икән, сине кешеләр дә кабул итәчәк. Мин үз-үземә ошыйм, мәсәлән. Ходай биргән борын, Ходай биргән күкрәк, кул, аяклар – барысы да. Шөкер, мин исән-сау, гариплектән Алла сакласын. Ә инде үзеңне үзгәртү темасына килгәндә, мин моңа каршы түгел. Кемдер иренен күпертә, кемдер күкрәген ясата. Ул юктан гына эшләми, барысы да кешенең комплексларына бәйле. Кеше үзенә ошамаган җирләрен үзгәртә. Андый кешеләрне бер дә гаепләмим. Һәркем үз тормышы өчен үзе җаваплы, Ходай каршысында үзе җавап бирәчәк.

Марсель ВӘГЫЙЗОВ, Татарстанның атказанган артисты:
– Ир-ат буларак, бер җире дә ясалмаган һәм, гомумән, бизәнмичә йөри торган хатын-кызлар күңелемә якынрак. Иреннәрен һәм башка әгъзаларын кабарткан затларны бөтенләй аңламыйм. Аллаһы Тәгалә безнең барыбызны да камил итеп яраткан. Без бит табигатькә сокланып йөрергә яратабыз. Чәчкәләрнең матурлыгына, һәркайсының үзенчәлекле булуына таң калып йөрибез. Үзебездән канәгать булмыйбыз икән, димәк, Аллаһ бары сине генә дөрес яратмаган, һәм син аның белән ризалашмаган булып чыгасың. Исламда да бу әйбергә катгый карыйлар, бу зур гөнаһ санала. Шуңа күрә минем фикерем дин белән тәңгәл килә.

Ләйсән МӘХМҮТОВА, Татарстанның атказанган артисты:
– Табигый матурлык модадан чыкмаячак. Һәм мин моны дөрес дип саныйм. Табигать уникаль кеше тудыра, башка берәүне тулысынча кабатлый торган бер генә кеше дә юк. Һәркемнең үзенә генә хас үзенчәлекләре була. Әмма 100 процентка үзен ошаткан кеше юктыр ул, минемчә. Булса да, бик аздыр алар. Әгәр кеше, үзен үзгәртеп, бәхетле була икән, бу начармыни? Үзгәртүләрнең дә төрлесе була бит. Кәкре яки зур борын, зур колаклар һәм башка шундый дефектлар кешегә яшәргә комачаулый, алар аркасында ул үзен кимсетелгән итеп хис итә икән, аның зыяны юк, миңа калса.

Ә инде бер үзгәреп, туктый алмыйча, нindидер ямьсез формаларга кереп китү – ул инде психологик тайпылыштыр. Әмма бу – мәсьәләнең бер ягы гына. Глобаль яктан карасаң, һәркем ирекле, үзенә кирәк икән, теләсә нәрсә эшләп бетерә. Ахырдан үкенечле генә булмасын…

Гүзәлем, җырчы:
– Мин дә шушы табигый матурлыкны яклаучылар сафында. Һәр кеше үзенчәлекле. Мине дә Аллаһы Тәгалә башкаларга охшамаган, матур кыяфәттә яраткан. Керфек һәм кашларга кадәр бер әгъзамны да үзгәрткәнем булмады. Бердәнбер нәрсә – тешләремне генә бераз матурладым. Кечкенәдән борчый иде алар мине. Гомумән, кешенең нинди дә булса зур комплекс тудыра торган урыны бар икән һәм ул аны үзгәртә ала икән, мин моңа каршы түгел. Кайбер очракларда ул бит бик җитди психологик проблемалар китереп чыгарырга мөмкин. Әйтик, кешенең үз-үзенә карата ышанычы кими, башкалар белән аралашканда читенсенә башлый. Монысы – бер хәл, ә инде тик торганнан, нindидер модага ияреп үзгәрүчеләрне аңламыйм. Шулай итә-итә, хатын-кызлар бер-берсеннән аерылмый башлады бит инде. Шөкер, соңгы арада табигый матурлыкка караш үзгәрә башлады кебек инде.

Гөлназ ШӘРИПҖАНОВА, җырчы:
– Хатын-кызлар турында сүз бара икән, күпчелеге, нәрсә генә эшләсә дә, үзләренә ошарга тырышалар. Әгәр ул үзен ничек бар – шулай ярата икән, бер җирен дә үзгәртми. Минем, мәсәлән, иреннәр кабартылган. Миңа андый иреннәр эффектлырак тоела, үземне шулай күрәм. Менә хәзер 35 яшем тулды, күзләр салынып төшә башлады. Аларны бераз ачып җибәрә торган процедура бар, шул рәвешле әзрәк яшәрергә була. Нишләп әле эшләтмәскә? Әмма 20 яшендә үзен үзгәртә башлаган, үзеннән «Барби» курчагы ясап куйган кызларны аңламыйм. Бәлки, кемгәдер бу һөнәре өчен кирәктер инде…

Белгеч фикере

Валерий ИВАНОВСКИЙ, клиник психолог:
– Тышкы кыяфәтне үзгәртү теләге нәрсә турында сөйли? Кеше башка төрле күзләр, зуррак иреннәр ясап, яңак сөягенә кадәр үзгәртә икән, ул үзен «юкка чыгарып», башка шәхес «ясарга» тырыша. Ә бу – кешенең үзе һәм тышкы мохиткә бәйлелеген югалтуы турында сөйли торган җитди «сигнал». Психология күзлегеннән, бу шактый көчле ассоциатив тайпылыш яки конверсион (истерик) тайпылыш диагнозын хәтерләтә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТОРМЫШ УЕНЫ

«ЯДӘЧ! ИСТӘ!» ФИЛЬМЫ ПРОКАТКА ЧЫГА

Премьера

Республика кинематографының бәхетле көннәре. Татарстан фильмнары бер-бер артлы Россия киноиндустриясен яулый. Әле күптән түгел генә режиссер Илшат Рәхимбайның «Микулай» этно-триллеры прокатка чыккан иде. Тиздән кинорежиссер Байбулат Батулланың «Ядәч! Истә!» («Бери да помни») фильмын да зур экраннардан карый алачакбыз.



kino-teatr.ru

Фильмны узган елның җәендә Балык Бистәсе районының Кече Әшнәк авылында төшергәннәр. Комедиядә Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты Роза Хәйруллина, Юныс Таиров, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Алмаз Хәмзин, Нияз Мөбарәкҗанов, Сирин Бәйрәмов, Алинә Насыйбуллина, Нурбәк Батулла һәм башкалар уйный. Сценарий авторлары – Байбулат Батулла, Таһир Минһаҗев, Дарья Беседина. Фильм 83 минут бара, яшь чикләве 12+.

«Ядәч! Истә!» – Байбулат Батулланың тулы метражлы фильм төшерүдә беренче тәҗрибәсе. Кинокартина «Короче» Россиякүләм фестивале дебют программасының төп конкурсында катнаша. Сүз уңаеннан, 2017 елда Байбулат Батулла әлеге фестивальдә «Половинки» кыска метражлы фильмы белән катнашып, «Иң яхшы сценарий» номинациясендә лауреат булган иде.

Серле уен

Фильмда төп символ булган уен турында бераз искәртеп китик. Ядәч – кошларда дуга сыман бөгелгән күкрәк сөяге.

Ядәч аеру – төрки халыкларда отыш уены. Ике кеше ядәчне аера да, шуннан соң бер-берсеннән әйбер алганда «исемдә» диярга тиеш була. Әгәр кулына әйбер алучы бу сүзне әйтергә онытса, әйбер биргән кеше «ядәч» дип кычкыра һәм җиңүгә ирешә.

Кино нәрсә турында соң? Бераз сюжетына да тукталыйк. Алты яшьлек Илһам җәйге каникулларын әби-бабасы янында авылда үткәрә һәм әти-әнисен бик сагына. Оныгының ничек тә күңелен күрү өчен, бабасы (Рабит Батулла) үзләренең чорында легендар булган «Ядәч! Истә!» уенын искә төшерә һәм оныгы белән уйнап карый. Баштарак бу Суфия әбекәйгә (Роза Хәйруллина) бер дә ошамый. Берзаман шул уенны уйнап, теләкләр чынга аша башлый. Тора-бара әлеге гадәти генә тоелган уен бер гаиләнең генә түгел, бөтен авылның тормыш-көнкүреше һәм хыялларын бик нык үзгәртә. Режиссер сүзләре белән әйтсәк, «Ядәч! Истә!» – тормыш ямен югалткан кешеләрдә яшәргә теләк уяну турында.

– Балачакта «Ядәч! Истә!» дигән уенны үзем дә еш уйный торган идем. Бик күңелле вакыт уздыру чарасы ул, – ди Байбулат Батулла. – Нигезендә әлеге уен кергән фильм турында 2015 елда ук уйлана башладым. Бу хакта язып та куйганмын. «Ядәч! Истә!» – кешеләрнең тормыш ямен югалтулары турында. Үзләренә кул селтәп, язмышка үпкәләүчеләр күп бит. Минем яшьтәшләр арасында да бар андыйлар. Хәер, үземнең дә «үпкә»ле чакларым була. Фильмда өлкән геройлар шактый булса да, анда сүз яшь турында бармый. Ул – яшәү ямен булдыру, яшәргә теләк уяну турында. Кешене алга барырга этәрә торган нәрсәне табуның никадәр мөһим булуы хакында. Уендагы ядәч ул – бары тик өмет символы гына. Без бит беренче уңышсызлыкка юлыгу белән үк хыялыбызны читкә куябыз. Теләсә кайсы хыялдан баш тартып була, ләкин моны эшләмәү яхшырак. Хыял, идея, максатларыңны истә тотып, аларны тормышка ашырырга кирәк.

«Фильмдагы бабай ул – безнең әти»

Әйтеп узганыбызча, фильмда Рәсим бабай ролен (төп герой) Байбулатның әтисе, күренекле язучы Рабит Батулла уйный. «Гаҗәп, әмма әти иң тыңлаучан артист булып чыкты», – ди Байбулат аның турында.

– Сценарийны язганда, мин безнең гаиләгә, әти белән әни арасындагы мөнәсәбәтләргә нигезләндем. Анда безнең балачактан алынган күренешләр күп. Мәсәлән, бабайның яшел суганнан сыбызгы ясавы. Абыем Нурбәк белән безнең күңелне әти шулай ача иде. Үзенең «Тычкан баласы Чикыл» әкиятеннән безгә шоу ясый иде. Әти әкият кенә сөйләп калмый, ә чыннан да тычкан барлыкка килгән кебек итеп эшли иде. Фильмдагы бабай ул – безнең әти инде, – ди Байбулат.

Режиссер сүзләренә караганда, фильм – өлкән яшьтәгеләр кризисы турында да.

– Без еш кына өч яшьлек баланың, яшүсмернең, урта яшьтәгеләрнең кризисы турында сөйлибез, ә өлкәннәр турында онытабыз. Әлбәттә, кризис олыгаюга гына бәйле түгел. Фильм үзенең аудиториясен тапсын иде. Беренче чиратта ул – гаилә, туганнар өчен. Шуңа күрә фильм яшь буынга да, өлкәннәргә дә кызыклы булыр дип уйлыйм.

«Ядәч! Истә!» кинокартинасы прокатка 14 сентябрьдә чыгачак.

Ләйсән САФИНА

Яңалык

Җанатар картасы

КЕМГӘ, НИЧЕК һӘМ НИ ӨЧЕН?

Россия Премьер-лигасы матчларына йөрү өчен, җанатарларга хәзер Fan-ID кирәк булачак. Гади итеп әйткәндә, җанатар картасы. Аны ничек ясатырга һәм кайдан алырга – шул хакта аңлатабыз.

rubin-kazan.ru

Нәрсә ул Fan-ID?

2023 елның 1 гыйнварыннан, законга кергән үзгәрешләр нигезендә, Россия Премьер-лигасы матчларына бару өчен, билет яки абонементтан кала, җанатар картасы да кирәк. Картаны Дәүләт хезмәтләре порталында электрон рәвештә алырга мөмкин.

Электрон картаны кәгазьгә чыгартырга кирәкми. Җанатар картасы һәр кешегә аерым, шул исәптән 14 яшькә кадәрге балаларга да кирәк. Соңгы мәгълүматларга караганда, Татарстанда җанатар картасын 11 мең кеше ясаткан.

Картаны ничек ясатырга?

Моның ике ысулы бар. Шарты бер: карта ясатырга җыенган кеше Дәүләт хезмәтләре порталында теркәлгән һәм аның шәхесе расланган булырга тиеш.

1 НЧЕ ЫСУЛ. Дәүләт хезмәтләре порталына кереп, «Җанатар картасы» хезмәтен сайлыйсы. Үзегез турында кирәкле мәгълүматны карап, тикшереп чыгасы, кирәк икән, төзәтмәләр кертәсе. Таләпләргә туры килгән фотосурәт урнаштырасы. Шуннан соң гаризаның статусы үзгәрергә, ягъни ул «актив» булырга тиеш. Гаризаның статусы үзгәргәч, күпфункцияле үзәккә барырга кирәк булачак. Монда карта рәсмиләштерүче кеше шәхесен раслатырга тиеш. Үзәк белгече барлык мәгълүматны тикшереп чыккач, порталдагы шәхси кабинетта карта пәйда булачак.

2 НЧЕ ЫСУЛ. Яңа үрнәктәге чит ил паспорты ияләре җанатар картасын күпфункцияле үзәккә бармыйча гына да ясата ала. Моның өчен порталда «Җанатар картасы» хезмәтен чит ил паспорты буенча рәсмиләштерү ысулын сайларга, алдарак санап үткән таләпләрне үтәргә, чит ил паспортының мәгълүматларын урнаштырырга кирәк. Биометрик мәгълүмат тикшерелгәч, карта шәхси кабинетта пәйда булачак.

Нәрсәне белеп торырга?

Җанатар картасы ярдәмендә сатып алынган билетны башка кешегә дә бирергә мөмкин. Моның өчен билетның булачак иясенең җанатар картасы номеры яисә телефоны, яисә электрон почтасы кирәк.

Шунысы да бар: Fan-ID барлык кешеләргә дә бирелми. Әгәр дә сез элегрәк җәмәгать тәртибен бозуда гаепләнгән яки сезгә карата административ тыю салынган кеше икән, картасыз калуыгыз да ихтимал.

Сүз уңаеннан

Узган якшәмбедә Казанның «Рубин» командасы «Оренбург» белән очрашкан иде. Исәп – 1:1 (Фамейе – Перес). Казан уенчылары, ике уен рәттән матч ахырында туп керттереп, өч очкосыз калды.

Очрашу тәмамлангач, «Рубин»ның баш тренеры Рәшит Рәхимов, җиңү китергән уеннар күбрәк ошый, диде диюен. Җиңелүгә нәрсә китерә икән соң?

– Билгеле, хаталар. Кызганыч, без кабат шул ук тырмага бастык һәм ахырда гол керттердек, – диде Рәшит Рәхимов. – Һәр уенга билгеле бер максатлар куясың, көндәшкә игътибар итәсең. Бу юлы безнең уен бөтенләй бүтән төрле иде. Футболчыларның янып торуын күрдем. Кайвакыт мондый хисләр тискәре нәтиҗә бирергә мөмкин. Командага хисләрне йөгәнләргә куштым.

Уенны, стадионга килеп, 4822 кеше караган («Ак Барс Арена»га 45379 тамашачы сыя).

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Кайсыгызның кулы җылы?

«ӘНИ, БЕЗ КАЙДА ЯШӘРБЕЗ?»

Яшел Үзән районының Большие Ключи авылында яшәүче Мәрдановлар гаиләсенә зур бәла килгән: аларның йортлары, янып, көлгә әйләнгән. Җиде балалы гаилә бернәрсәсез урамда калган.

– 24 июньдә кичке якта булды бу хәл. Ул көнне без барыбыз да иремнең апаларына мунчага дип барырга чыккан идек. Өйдән чыгып китеп, 20–30 минут вакыт узгач, күршебез: «Йортыгыз яна», – дип шалтыратты. Ирем шундук өйгә йөгерде. Мин аның артыннан кайттым, – дип ул көнне искә алды Гөлүсә ханым. – Без кайтып кергәндә, йорт эче төтен белән тулган иде. Документларны гына алып чыга алдык. Тиз арада өебез янып та бетте.

Гөлүсә ханым әйтүенчә, балаларның иң зурысына – 13, кечкенәсенә – 4 яшь. Йортлары янгач, гаилә бер атна тирәсе туганнарында яшәгән. Хәзерге вакытта алар фатир арендалап тора.

– Йортның стеналары гына утырып калды. Башта яңартмакчы идек, килеп чыкмаслыгын аңлагач, анысын да сүттек, – ди Гөлүсә Мәрданова. – Матур гына яшәп ятканда бернисез калу бик авыр, әлбәттә. Беренче уй «Кая барырбыз? Нишләрбез икән?» булды. Балалар аеруча нык борчыла. Янгын булган көнне дә, аннан соң да бертуктаусыз: «Әни, без кайда яшәячәкбез?» – дип кабатладылар. Әле ярый ул көнне беребез дә өйдә юк иде. Иң мөһиме – барыбыз да исән-сау.

Йортлары янган гаилә белән район башлыгы Михаил Афанасьев та очрашкан. Булдыра алганча ярдәм итәргә вәгъдә биреп озаткан да «Ханский дом» оешмасы җитәкчесе Ильяс Гыймадовка мөрәҗәгать иткән. Шуннан соң эшмәкәр социаль челтәрләрдә акча җыюны оештырган. Җыелган акчага гаиләгә йорт салып бирәчәкләр. Йортны сафка бастырыр өчен якынча 4–5 млн сум акча кирәк икән. Хәзерге вакытта счетта 1 миллион сум тирәсе акча җыелган. Төзелеш эшләре инде башланып та киткән. Ниятләре – суыклар башланганчы гаиләне яңа, матур йортлы итү. Йорт каркаслы булачак. Хәзерге көндә аның идәннәрен җәяләр. «Иң мөһиме – балаларга яшәр өчен тиз арада уңайлы шартлар тудыру», – ди Ильяс Гыймадов.

– Яшел Үзәннән дә вакытлыча торып торырга фатир тәкъдим иткәннәр иде, тик балалар өчен уңайсыз була, дип уйлаштык. Алар шушы авыл мәктәбенә укырга йөри. Ирем Марсель дә Карагуҗа авылына барып эшли. Мин бу фаҗига булганчы кибеттә эшли идем, хәзер буш вакыт күп кирәк булганлыктан, аннан киттем. Вакытлыча башка эшкә урнаштым. Авылдашларга, безне бер белмәгән кешеләргә, район башлыгына бик зур рәхмәт. Безне кайгыбыз белән ялгыз гына калдырмадылар. Акчалата да, киемнәр белән дә ярдәм иттеләр. Социаль челтәрләрдә әле дә акча җыю дәвам итә, – диде ул. – Бу кадәр игътибар булыр дип көтмәгән дә идек. Йорт салырга ярдәм итүләрен белгәч, сөенечтән нишләргә белмәдек. Бик зур рәхмәт. Кышка кергәнче яңа йортка күченергә хыялланабыз.

Янгыннан зыян күргән гаиләгә ярдәм җыю әле дә дәвам итә. Теләге булганнар акчаны Мәрданова Гөлүсә исемендәге картага күчерә ала. Ул **89393748584** (Альфа Банк) номерындагы телефон картасына беркетелгән.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5129 данә
Гомуми тираж – 14057 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 309

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+